СИШӘМБЕ
20 ФЕВРАЛЬ
1940 ел
№ 41 (5841)
Аерым номеры 10 тиен

БАРЛЫК ИЛЛӘРНЕҢ ПРОЛЕТАРИЙЛАРЫ, БЕРЛӘШЕГЕЗ!

КЫЗЫЛ ТАТАРСТАН

ВКП(б) Өлкә Комитеты, Шәһәр Комитеты, ТАССР Верховный Советы һәм Шәһәр Советы органы.

РЕДАКЦИЯ АДРЕСЫ:
Казан, Матбугат йорты.
ТЕЛЕФОННАР: экономик бүлек 18—22, авыл хуҗалыгы һәм совет төзелеше бүлекләре 4—58, партия бүлеге һәм матбугат күзәтү бүлеге 14—75, хатлар бүлеге 21—28, культура бүлеге 18—22, информация бүлеге 5—86, төнге редакция 3—73, типография 36—60, бухгалтерия һәм игланнар бүлеге 2—19.

ОТЧЕТ-САЙЛАУ ҖЫЕЛЫШЛАРЫН ТАГЫН ДА АКТИВРАК ҺӘМ ОЕШКАНРАК ҮТКӘРИК!

Башлангыч партоешмаларда отчет-сайлау җыелышлары зур оешканлык һәм активлык белән бара. Коммунистлар, ВКП(б) ның XVIII нче съезды карарларының һәм иптәш Сталин күрсәтмәләренең үз оешмалары тарафыннан ничек итеп тормышка ашырылуына йомгак ясыйлар. Алар оешманың эшендәге уңышларны күрсәтү белән бергә, большевистик тәнкыйть һәм үзеңне тәнкыйтьләү нигезендә оешманың һәм аның җитәкчеләренең эшендәге кимчелекләрне, тулылыгы белән ачып салалар. Партоешмаларда отчет-сайлау җыелышларының барышы турында газетабызда урнаштырылган материалларның күбесе әнә шул турыда сөйлиләр.

ВКП(б) райкомнары тарафыннан җитәкчелек һәм хәзерлек эшләре яхшы булган урыннарда отчет-сайлау җыелышлары оешкан рәвештә, зур активлык белән, идея-политик яктан югары дәрәҗәдә үтәләр. Ләкин ачык итеп әйтергә кирәк: партиянең кайбер район комитетлары һәм башлангыч оешмаларның җитәкчеләре отчет-сайлау җыелышларының никадәр зур политик әһәмияткә ия булуын төшенеп җитмәгәннәр, аңа тиешенчә хәзерләнмәгәннәр. Андый җыелышларда оешканлык, активлык җитәрлек түгел, тәнкыйть һәм үзеңне тәнкыйтьләү түбән, оешманың һәм аның җитәкчеләренең эшендәге төп кимчелекләр ачып салынмыйлар. Акташ районы Советы башкарма комитеты янындагы башлангыч партоешмада булып үткән отчет-сайлау җыелышы моңа ачык мисаль булып тора. Бу оешмада отчет-сайлау җыелышы, райком вәкиле Куликовның таләбе буенча, билгеләнгән сроктан бер көн элек үткәрелә. Шуның нәтиҗәсендә партоешма секретаре иптәш Васильева отчет докладына тиешенчә хәзерләнә алмый. Билгеле, бу доклад коммунистларны һич тә канәгатьләндерми. Җыелышта активлык, тәнкыйть һәм үзеңне тәнкыйтьләү түбән дәрәҗәдә була. Оешманың эшендәге җитешсезлекләр ачылмый калалар.

Вишне-Поляно авыл советы (Октябрь районы) янындагы партоешма секретаре иптәш Карпов та отчет докладын хәзерлексез ясый. Ул, ВКП(б) ның XVIII нче съезды карарлары партоешма тарафыннан ничек тормышка ашырылуы турында бер сүз дә әйтмәгән.

Партиянең җитәкче органнарын сайлау җыелышлары ВКП(б) Үзәк Комитетының бу турыдагы инструкциясе нигезендә үткәрелергә, партия демократиясен бозуларга һич тә юл куелмаска тиеш.

Ләкин, кайбер башлангыч партоешмаларда сайлау җыелышлары вактында ВКП(б) Үзәк Комитетының инструкциясен бозу фактлары бар. ВКП(б) ның Теләче райкомы янындагы башлангыч партоешмада үткәрелгән җыелышы моңа ачык мисаль була ала. Бу җыелышта райкомның җитәкче работниклары үзләре катнашуга карамастан „партиянең җитәкче органнарын сайлаулар" турында ВКП(б) Үзәк Комитетының инструкциясен тупас рәвештә бозалар. Анда отчет доклады буенча карар кабул итмичә торып, сайлау үткәрәләр.

Партоешмалар үзләренең җитәкче органнарын сайлаулар вактында кадрлар сайлап алу турында ВКП(б) Үзәк Комитетының һәм бөек юлбашчыбыз иптәш Сталинның күрсәтмәләреннән чыгып эш итәргә тиешләр. Кадрлар сайлап алу ни дигән сүз? Ул „...работникларны, беренчедән, политик билге буенча, ягни алар политик яктан ышанычлылармы һәм, икенчедән, эшлеклелек билгесе буенча, ягни алар фәлән төрле конкрет эш өчен яраклылармы дигән билге буенча сайлап алу дигән сүз" (Сталин).

Ләкин, кайбер вакытларда, бездә кадрлар сайлап алуда менә шушы большевистик принциптан чыгып эш ителми. Шуның аркасында ялгышулар килеп чыга. Мәсәлән, үткән сайлаулар вактында сайланган иптәшләрнең кайберләре озак та үтмичә булдыксызлыклары һәм партия эшен таркатуга китерүләре өчен җитәкчелектән алындылар. Сталин районында, Главлессбыт партоешмасы секретаре Фазлиев, Казан станциясенең вагон цехында партоешма секретаре Голодев һәм Киров районы, „Красное Знамя" күн заводы партоешмасы секретаре Халитов иптәшләр коммунистларның ышанычын аклый алмаулары өчен, бу сайлауларда яңа составка кертелмәделәр. Отчет сайлау җыелышлары 25 нче февральгә кадәр дәвам итә. Үткән сайлаулар вактында аерым партоешмалар тарафыннан җибәрелгән мондый ялгышлар искә алынырга һәм алар кабатланмаска тиеш. Партиянең җитәкче органнарын сайлаулар вактында яңа составка кандидатуралар күрсәтү һәм тикшерү эше тагын да яхшырак итеп оештырылырга тиеш.

Безнең партоешмаларыбызның күпчелеге бу сайлауларга зур уңышлар белән килделәр. Алар үзләренең сафларын алдынгы эшчеләр, колхозчылар һәм совет интеллигенциясе хисабына нык кына тулыландырдылар, коммунистлар идея - политик яктан нык үстеләр. Кадрлар сайлап алуда, хуҗалык һәм культура эшләренә җитәкчелек итү эшендә бай тәҗрибәләр тупладылар.

Отчет-сайлау җыелышларында партоешмаларның җитәкчелегенә иң яхшы иптәшләр—Ленин—Сталин партиясе эшенә чын күңелдән бирелгән, эшкә сәләтле, инициативалы, уяу, тотнаклы большевиклар сайланырлар.

Барлык партоешмаларда да отчет - сайлау җыелышлары идея-политик яктан югары дәрәҗәдә үтәр һәм ул, ВКП(б) ның XVIII нче съезды тарафыннан илебез алдына куелган бөек бурычларны үтәүгә хезмәт ияләре массасының иҗади активлыгын һәм инициативасын тагын да ныграк күтәрер, аларны коммунизм тантанасы өчен көрәшкә тагын да ныграк туплар.



Фин ак гвардеецларына каршы сугышларда катнашучы — Советлар Союзы Герое, кече командир Г. М. Лаптев. М. Редкин фотосы (ТАСС фото-клишесе).

ССР СОЮЗЫ ОРДЕННАРЫ ҺӘМ МЕДАЛЬЛӘРЕ ТАПШЫРУ

17 нче февральдә СССР Верховный Советы Президиумы Председателе иптәш М. И. Калинин бүләкләнүчеләргә орденнар һәм медальләр тапшырды.

Хөкүмәтнең сугыш заданиеләрен үрнәк булырлык итеп үтәгән өчен һәм шул вакытта кыюлык һәм батырлык күрсәткән өчен Кызыл Армия сугышчыларының, командирларының һәм политработникларының зур группасына бүләкләр бирелә. Бүләкләнүчеләр арасында политрук иптәш В. Ф. Баранов, 3 нче ранг военврач иптәш Л. Н. Васильев, кече политрук иптәш И. П. Сердюков һәм башка күп кенә иптәшләр бар.

Фин ак гвардеецларына каршы көрәш фронтында командованиенең сугыш заданиеләрен үрнәк булырлык итеп үтәгән өчен һәм шул вакытта кыюлык һәм батырлык күрсәткән өчен бүләкләнүчеләргә орденнар һәм медальләр бирелә. Бүләкләр майор иптәш Ф. П. Мотылевка, өлкән политрук иптәш Б. П. Степановка, кече лейтенант иптәш А. Н. Погребнякка һәм башкаларга бирелде.

Бүләкләнгән хәрби работниклар исеменнән В. Ф. Баранов, Н. И. Работкин, Н. А. Цытович һәм Ф. П. Мотылев иптәшләр партиягә, хөкүмәткә һәм бөек Сталинга чын күңелдән рәхмәт белдереп речь сөйлиләр. Алар халык эше өчен, Ленин—Сталин партиясе эше өчен киләчәктә дә нык һәм батырларча сугышырга вагдә бирделәр.

Иптәш Работкин болай диде:

— Михаил Иванович, безнең, социализм иле сугышчыларының, Эшче-Крестьян Кызыл Армиясе антын намус белән үтәячәгебезгә Сезнең аркылы бөтен Совет халкын ышандырырга рөхсәт итегез.

СССР ның Ленин орденлы зур Академия театры дирижеры, атказанган сәнгать эшлеклесе А. Ш. Мелик-Пашаевка Ленин ордены бирелә. Ул әрмән театр һәм музыка сәнгатен үстерү эшендәге күренекле уңышлары өчен бүләкләнгән.

Болардан тыш хәрби, хуҗалык һәм культура работникларының бүләкләнгән тагын бер группасына орденнар һәм медальләр бирелә.

Бүләкләнүчеләргә орденнар һәм медальләр тапшырганнан соң иптәш М. И. Калинин бу иптәшләрне югары бүләк алу белән котлады һәм аларның алдагы эшләрендә чын күңелдән яңа уңышлар теләде.

(ТАСС).

МТС һәм МТМ алдынгыларының РЕСПУБЛИКА ПОЧЕТ ТАКТАСЫ

Тракторларга һәм авыл хуҗалыгы машиналарына ремонт ясауда яхшы күрсәткечләр бирүче алдынгыларның һәм стахановчыларның республика почет тактасына ВКП(б) райкомнары һәм хезмәт ияләре депутатларының район советлары башкарма комитетларының күрсәтүләре буенча кертеләләр:

21. Чүпрәле МТС ының трактор бригадасы бригадиры орденлы иптәш **З. А. Алимов.** Аның бригадасы үзенә беркетелгән тракторларга һәм авыл хуҗалыгы машиналарына ремонт ясауны 1939 нчы елның 15 нче декабренә төгәлләде.

22. Яңа Чишмә районы, Черемуховский МТС ының трактор бригадасы бригадирлары **И. В. Хорьков** һәм **Г. Г. Михайлов** иптәшләр. Бу бригадалар тракторларга һәм авыл хуҗалыгы машиналарына ремонт ясауны 1940 нчы елның 20 нче январена төгәлләделәр.

23. Тымытык районының Вахитов исемендәге совхоз токарьлары **Г. Галимов** һәм **Г. Инников** иптәшләр ремонтта норманы көн саен 250 процент үтиләр.

24. Аксубай МТС ының токаре иптәш **С. Г. Краснов** ремонтта норманы системалы рәвештә 300—500 процент үти.

25. Әтнә МТС ының 7 нче номерлы трактор бригадасы бригадиры иптәш **С. Гайнеттинев.** Аның бригадасында тракторларга ремонт ясау 1939 нчы елның 30 нчы декабренә төгәлләнде.

26. Чүпрәле МТС ының тракторчылары **А. Камалов, Х. Низаметтинов, Н. Җаббаров, Х. Исхаков** иптәшләр үзләренә беркетелгән тракторларга ремонт ясауны 1939 нчы елның 15 нче декабренә төгәлләделәр.

27. Яңа Чишмә районы, Черемуховский МТС ының тракторчысы иптәш **А. Потемкина** үзенә беркетелгән тракторга һәм тагылма инвентарьларга ремонт ясауны 1940 нчы елның 20 нче январена төгәлләде.

ЛЕНИНГРАД ХӘРБИ ОКРУГЫ ШТАБЫНЫҢ ОПЕРАТИВ СВОДКАСЫ

17 нче февральдә Карелия бугазында безнең частьләрнең удары астында дошман зур югалтуларга дучар булып, авылларны яндырып, ашыгыч рәвештә Выборг ягына таба һәм анардан көнчыгышка таба чигенде.

Безнең частьләр **Ойнола** шәһәрен (Муола-ярви күленең төньяк ярында), **Выборгдан 6** километр көнъяк-көнчыгыштарак **Сяиние** станциясен, **Сумма** районыннан көнбатыштарак ныгытылган **Кархула** узелын һәм Приморье районында **Нярья** һәм **Мурила** шәһәрләрен алдылар.

Бөтен фронтта дошманны эзәрлекләү дәвам итә.

Фронтның башка участкыларында әһәмиятле бер нәрсә дә булмады.

Безнең авиация дошман гаскәрләренә һәм аның сугыш объектларына актив хәрәкәтләр алып барды.

* * *

18 нче февральдә Карелия бугазында безнең һөҗүмебез уңышлы рәвештә киңәюдә дәвам итте. Безнең частьләрнең басымы астында дошман чигенүдә дәвам итә.

Безнең частьләр **Вуокси-ярви** һәм **Яюряпяян-ярви** күлләре арасында **Салмен-кайта** елгасына чыктылар һәм **Муола** авылын һәм андагы ныгытылган пунктны, Приморье тимер юлында **Выборгдан** 10 километр көньяктарак **Соммэ** станциясен, **Юханнес** шәһәрен һәм Приморье тимер юлының **Максалахти** станциясен алдылар һәм шулай итеп **Виорке** атавыннан төньяктарак фин култыгының көнбатыш ярына килеп чыктылар.

17 һәм 18 нче февральдә безнең гаскәрләр дошманның ныгытылган 313 оборона пунктын алдылар, шуларның 41 е тимербетоннан ясалган артиллерия корылмалары. 11 нче февральдән 18 нче февральгә кадәр безнең гаскәрләр дошманның барлыгы 475 ныгытылган оборона пунктын алдылар, шуларның 92 се тимербетоннан ясалган артиллерия корылмалары.

Фронтның башка участкыларында әйтерлек үзгәрешләр юк.

Безнең авиация дошман гаскәрләренә һәм аның сугыш объектларына сугыш хәрәкәтләре алып барды. Һавада булган сугышларда дошманның 21 самолеты бәреп төшерелде.

Чит илләрдә

Ак финнәргә сугыш ярдәме күрсәтүдән Швециянең баш тартуы

ЛОНДОН, 17 февраль. (ТАСС). Маннергеймга сугыш ярдәме күрсәтүдән баш тарту турында Швеция хөкүмәте тарафыннан беренче тапкыр ясалган белдерү Лондон даирәләрендә тирән тәэсир калдырды. Бу белдерүне Кызыл Армиянең куәтенә карата соңгы атналарда шикле чыганаклардан таратыла торган уйдырмаларга Швеция хөкүмәтенең алданмавы билгесе дип карыйлар. Лондон даирәләренең бөтен игтибары Таннерның Финляндиягә гаскәрләр җибәрүне сорап союзникларга мөрәҗәгат итәчәге турындагы ачыктан-ачык белдерүенә туплана.

Швеция хөкүмәтенең икенче белдерүенә, ягни чит ил гаскәрләренә Швеция территориясе аркылы үтәргә рөхсәт бирә алмаячагы турындагы белдерүгә Таннерның союзникларга карата югарыда әйтелгәнчә мөрәҗәгат итәчәген аңлату дип карыйлар. Кичә Лондон журналистлары Таннер үзенең мөрәҗәгатен союзникларга тапшырганмы һәм тапшырган булса аңа ничек караганнар дигән мәсьәлә белән аеруча кызыксындылар. Ләкин бу турыда шушы вакытка кадәр бер нинди хәбәр юк.

Чит ил гаскәрләренә Швеция территориясе аркылы үтәргә рөхсәт бирелмәячәклек турында Швеция хөкүмәтенең Британиш Юнайтед Пресс агентлыгы тарафыннан тапшырылган белдерүен кичә бер генә кичке газета да басып чыгармады.

Швециянең баш министре Гансонның белдерүе

СТОКҺОЛЬМ, 17 февраль. (ТАСС). Швеция телеграф агентлыгы түбәндәге белдерүне тапшыра: „Финляндиянең Швециядән ярдәм соравы турында матбугат хәбәрләрен аңлату өчен Швециянең министрләр советы председателе Гансон түбәндәгеләрне белдерде: „Финляндия хөкүмәте Швеция хөкүмәтеннән төрле сугыш кирәк-яраклары китерүне күп тапкырлар үтенгән иде. Бу үтенечләрне гадәттә канәгатьләндерергә мөмкин булыр иде. Шулай ук сугышта яраланганнарны һәм инвалидларны Швециядә дәвалау турындагы һәм Швециядән Финляндиягә эшчеләр җибәрү турындагы мәсьәләләр дә тикшерелде. Бу уңай белән чаралар күрелде. Финляндия хөкүмәтенең кайбер членнары Стокһольмда булган вакытта Финляндиягә турыдан-туры сугыш ярдәме күрсәтү турындагы мәсьәлә куелды. 13 нче февральдә Финляндиянең чит ил эшләре министре бу мәсьәләне Швециянең баш министре, чит ил эшләре министре һәм хәрби министре белән берлектә тикшерде. Финляндия ягы Швециянең хәрби частьләрен Финляндиягә җибәрүне таләвен белдерде. Швеция ягы исә Швециянең Финляндиягә ярдәме турында баш министрнең 17 нче январьда риксдагка биргән декларациясендә аңлатылган директиваларын искә төшереп үтте. Бу декларация гомуми рәвештә яхшы дип табылган иде. Ул вакытта белдерелгән караштан һичбер үзгәреш килеп чыкмады".

Сугыш уты кабызучыларның Швециягә басымы

СТОКҺОЛЬМ, 18 февраль. (ТАСС). Кызыл Армиянең соңгы җиңүләренең күләме һәм әһәмияте, Маннергейм бандаларының тулысынча тар-мар ителү перспективалары ачыклана барган саен Англия—Франция дипломатиясенең Стокһольмдагы һәм Ослодагы активлыгы көчәйгәннән-көчәя бара. Шушы көннәрдә генә Италиянең „Пополо д' Италия" газетасының хәбәр итүенә караганда, „Англия Швецияне Россиягә карата тагын да дошманрак позициягә басарга мәҗбүр итү өчен ялкынны көчәйтә". Швеция хөкүмәте политикасына Англиянең һәм Франциянең ачыктан-ачык катнашулары уңае белән, Швецияне нейтралитеттан баш тартырга мәҗбүр итүне һәм аны Англия—Франция блогы ягында торып сугышка тартуны турыдан-туры максат итеп куйган катнашу уңае белән Швециянең күп төрле җәмагать даирәләрендә тирән тынычсызлану сизелә. Англия—Франция блогы тактикасының чын мәгънәсе монда бер нинди шик тудырмый: ак финнәргә ярдәм итү сылтавы астында Англия—Франция сугыш блогы чынлыкта Скандинавияне үз политикасына тарту өчен көрәшә, Германиягә каршы сугыш фронтын төньякка таба киңәйтергә һәм бер үк вакытта маглүм бер моментта Ленинградка удар ясау өчен үзенең Финляндия плацдармын саклап калырга маташа. Француз „социалистлары" органы „Популер" газетасының лыгырдык язучыларының шушы көннәрдә генә „Скандинавия хәленең ачкычы булып кала" дип белдерүләре юкка гына түгел.

Швеция реакционерлары һәм аларның социал-демократлар лагерындагы иярченнәре үз хуҗаларының директиваларын үтәү өчен аеруча оятсыз һәм рәхимсез „көрәшүчеләр" булып чыктылар. Аларның күбесе, хәзер ачык маглүм булганча, инде күптәннән бирле Англия разведкасыннан акча алып ятканнар. Алар Швециянең милли һәм дәүләт бәйсезлеге интересларын мәсхәрәлиләр һәм „Швеция хөкүмәтенең союзникларның теләген үтәүче булып әверелүен" таләп итәләр.

Хәзер „активистлар" башлыгы булырга тырышучы атаклы Сандлер бер төркем кешеләр җыеп, алар ярдәме белән Швециянең нейтралитетын өзүгә һәм бетерүгә һәм Швецияне сугышка тартуга юнәлдерелгән провокацион эш алып бара. Полковник Братт һәм „Профессор" Анлунд дигән кешеләрнең аннан-моннан бер китап әвәләп чыгаруларында да аның катнашы булган. Бу китапта алар Швеция гаскәрләрен Финляндиягә җибәрергә турыдан-туры һәм ачыктан-ачык чакыралар.

Ләкин Швеция халкының һәм дәүләтенең бу явыз дошманнарының шау-шуы алар өчен кирәкле нәтиҗәләргә китермәде. Маглүм ки, Швеция армиясен хәзер үк Финляндиягә җибәрү турында Маннергеймның таләбеннән Швеция хөкүмәте баш тартты. Шуннан соң бөтен провокаторлар өере хөкүмәткә каршы кампания җәелдерде. Күп кенә бульвар листоклары, хөкүмәт Маннергейм таләпләрен үтәүдән баш тартуы турындагы карарны хәрби даирәләр белән дә, чит ил эшләре комитеты белән дә киңәшләшмичә кабул иткән дип һәм хөкүмәттә „диктатура" башланган дип хәлдән таеп акырына башладылар.

Икенче яктан, авторитетлы даирәләрдә күрсәтелгәнчә, соңгы көннәрдә турыдан-туры Лондоннан булган күрсәтүләр буенча Англия—Франциянең Швециядәге агентурасы Гансон хөкүмәтен „көчле кул" хөкүмәте белән, ягни сугыш уты кабызучыларның теләгән һәм планнарын һич сүзсез үтәрлек хөкүмәт белән алмаштыру лозунгысын күтәргән.

Һәр төрле күренешләрне күргән күзәтүчеләр Швеция хөкүмәтенә булган басым бу өлкәдә хәзергә кадәр маглүм булган фактларны узып китте дип раслыйлар. Моңа ышану өчен Швеция хөкүмәтенә карата Англия—Франция агентлары куллана торган янауларның характерын күрсәтү генә дә җитә... Мәсәлән, әгәр Швеция хөкүмәте үзенә „тәкъдим ителә" торганнарга „ирекле" рәвештә риза булмаса, Швецияне гүяки „союзниклар"ның интересларына нык кагыла торган нейтралитет политикасын өзәргә „союзниклар"ның барыбер мәҗбүр игәчәкләре белдерелә. Соңгы көннәрдә түбәндәгечә „янау"да ходка җибәрелде: әгәр Швеция ак Финляндиянең таләпләрен канәгатьләндермәсә, ул чагында гүяки, Финляндия „хөкүмәте" Советлар Россиясе белән шундый „солых"ка риза булачак ки, бу „солых" „Швециянең интересларына куркыныч тудырачак".

Швециянең күпчелек халкы, барлык дөрес фикер йөртүче политиклар Швеция халкының тыныч хезмәтен җимерүне һәм кайбер державаларның интереслары хакына аны сугышка куып кертүне үзләренең бурычлары итеп куйган дошманнарның Швецияне кая тартырга маташуларын яхшы аңлыйлар.

(Телеграммаларның ахры 4 нче биттә).

ПАРТИЯ ОЕШМАЛАРЫНДА ОТЧЕТ-САЙЛАУ ҖЫЕЛЫШЛАРЫ

БОЛЬШЕВИСТИК ОЕШКАНЛЫК

Мехкомбинат коммунистлары партоешманың отчет-сайлау җыелышына гаять зур күтәренкелек белән җыелдылар. Аларның һәммәсендә дә бер теләк—отчет чорындагы эшне партиябезнең XVIII нче съезды карарларын үтәү йөзеннән карап тикшерү, ирешелгән уңышларга йомгак ясау, кимчелекләрне большевикларча ачу, киләчәк өчен конкрет юллар сызу һәм партбюроның яңа составына сыналган һәм иң эшлекле коммунистларны сайлау.

Җыелыш оешкан рәвештә башланды. Җыелышта ВКП(б) Өлкә Комитетының секретаре Алемасов һәм Шәһәр Комитеты секретаре Гаязеттинов иптәшләр катнаштылар.

Патбюро секретаре иптәш Кузьмин үзенең докладында иң элек, илебездәге тарихи вакыйгаләргә, ВКП(б) ның XVIII нче съезды тарафыннан куелган бөек бурычларга тукталды.

Партоешма алдында торган төп бурычларның берсе—предприятие администрациясенең эшенә контрольлек итү хокукын тормышка ашыру. Партбюро бу мәсьәлә белән җидди рәвештә шөгыльләнгән. Политик бурычларны хуҗалык эшләре белән дөрес бәйләп алып бару нәтиҗәсендә, Мехкомбинат коллективы 1939 нчы елның производство планын срогыннан алда, яхшы күрсәткечләр белән, арттырып үтәүгә ирешкән. Партоешма, барыннан да элек, ВКП(б) ның XVIII нче съезды материалларын киң массага тирәнтен аңлату эшләрен оештырган, фабрикаларда һәм цехларда төп җитәкче кадрларның дөрес урнаштырылуын тәэмин иткән, производствода коммунистларның һәм комсомолецларның авангардлык рольләрен күтәрү өчен көрәшкән. Стахановчы вахталар оештыру һәм алдынгыларның эш тәҗрибәләрен уртаклашу производстводагы эчке мөмкинлекләрне тагын да күбрәк ачуга ярдәм иткән.

Шулай да әле хуҗалык эшенә җитәкчелек итүдә зур кимчелекләр бар. Комбинатта хезмәт дисциплинасын ныгыту өчен көрәш җитәрлек түгел. Күп станокчылар хәрәкәтен җәелдерү эше акрын бара. 10 гына кеше күп станокта эшләүгә күчкән. Күп профессияне үзләштерү хәрәкәте дә йомшак җәелдерелә.

Комбинатта большевистик кадрлар тәрбияләү буенча шактый эшләр үткәрелгән. Отчет чорында алдынгы стахановчылардан 92 кеше хуҗалык эшләренә җитәкчеләр итеп күтәрелгән. Шулар арасында партия членнары һәм кандидатлары 50 кеше. Ләкин әле кайбер эш тармакларында (механический заводта, 3 нче фабрикада) кадрларны тәрбияләп үстерүгә һәм яңа күтәрелгән кадрларга системалы ярдәм оештыруга җитәрлек игтибар бирелми.

Башлангыч партоешма 1939 нчы елны ВКП(б) сафларына 99 кандидат һәм 53 член кабул иткән. Ләкин төп профессия эшчеләре һәм хатын-кызлар исәбенә үсеш бик аз. Оешмада, кандидатлык стажлары үткән 68 кеше бар. Бу саннар коммунистларны, бигрәк тә кандидатларны тәрбияләү һәм аларны актив эшкә тарту буенча канәгатләнерлек эш алып барылмаганлыкны күрсәтәләр.

Партоешмада барлыгы 230 член һәм 158 кандидат бар. Шулардан 179 член һәм 104 кандидат партия тарихын үзлекләреннән өйрәнә. ВКП(б) тарихын өйрәнүнең барышына килгәндә, мактанырлык эш юк. Күп кенә иптәшләр II—III нче бүлекне генә укыганнар. Интеллигенция һәм комсомолецлар арасында ВКП(б) тарихын өйрәнү эше тагын да начаррак тора. Үзлекләреннән өйрәнергә белемнәре җитмәгән иптәшләр өчен 6 түгәрәк оештырылган булса да, аларның 5 сендә занятиегә йөреш 50—60 проценттан артмый.

Доклад буенча фикер алышуларда 31 кеше катнашты. Сөйләүчеләр партоешманың уңышларын күрсәтү белән бергә күп кенә кимчелекләрне ачып салдылар.

Иптәш Бенштох, партия сафларына яңа кабул ителгәннәр белән эшләүгә, партдисциплинаны ныгытуга җитәрлек игтибар ителмәвен әйтеп үтә. Кандидатлар белән беседалар бик сирәк үткәрелә. Кайбер членнар һәм кандидатлар 5—6 ай буена партҗыелышка килмәгәннәр, партпоручениеләрне үтәүгә салкын караганнар, партвзносларны вактында түләмәгәннәр.

— Партбюро,—ди иптәш Н. С. Иванов, — большевистик тәнкыйтьне җәелдерүгә, бигрәк тә газета хәбәрләренең нәтиҗәлелеге өчен көрәшкә ныклы игтибар бирмәде. „Мехчы“ газетасының 60 һәм „Меховщик“ның 50 хәбәренә хуҗалык җитәкчеләре тарафыннан җавап бирелмәгән. Кайбер коммунистлар тәнкыйтьләгәнне яратмыйлар. Бер вакыт мин ФЗУ мәктәбе директоры Салминны тәнкыйтьләп язган идем. Шуннан соң ул байтак вакыт сөйләшмичә йөрде.

Фикер алышуларда катнашучы күп кенә иптәшләр аерым коммунистлар белән эшләүгә, комсомол оешмасына җитәкчелекне көчәйтергә кирәклеген күрсәтеп үттеләр.

Җыелыш партбюроның эшен канәгатләнерлек дип тапты һәм киләчәк эш өчен конкрет карар кабул итте.

У. Ахметов.

КОММУНИСТЛАР КОНКРЕТ ТАКДИМНӘР КЕРТТЕЛӘР

Язу машиналары заводында партия оешмасының отчет-сайлау җыелышы ике көн дәвам итте.

Фикер алышуларда катнашучы коммунистлар партия оешмасының уңышларын күрсәтү белән бергә, бюроның эшендә булган җитешсезлекләргә дә тукталдылар.

Партбюро ВКП(б) ның XVIII нче съездыннан соң заводның хуҗалык эшләре белән шөгыльләнә башласа да, бу өлкәдә партия оешмаларына бирелгән хокуклардан тулы файдаланмады. Мәсәлән, үткән елның июль аенда бюро механика цехының эшен тикшереп, конкрет карар кабул итте. Бу карарны тормышка ашыру цехның эшендә зур гына борылыш ясады. Цех планны үти һәм арттырып үти башлады, стахановчылар саны артты, продукциянең сыйфаты яхшырды. Ләкин соңгы вакытта цех тагын да өзеклектә. 1940 нчы елны ул хәзерлексез каршылады, январь аенда планны үтәмәде. Цехның җитәкче работниклары—коммунистлар Солдатенков, Викторов һәм Москвин иптәшләр цехның эшен юлга салу турында тиешенчә кайгыртмыйлар.

Партиянең эчке эше өлкәсендә дә кимчелекләр бар. Бюро коммунистлар арасында тәрбия эшләрен җитәрлек алып бармады. Үткән ел партия документларын югалту, аерым коммунистлар тарафыннан хезмәт дисциплинасын бозу фактлары булды.

Патрбюроның эшендә булган бу һәм башка җитешсезлекләр җыелышта кискен тәнкыйть уты астына алындылар. Коммунистлар үзләренең чыгышларында партия оешмасының эшен киләчәктә яхшырту буенча күп кенә кыйммәтле такдимнәр бирделәр.

Җыелыш оешманың эшен канәгатләнерлек дип тапты.

Г. Кушаев.

МТС коммунистлары җыелышында

Әлмәт МТС ы янындагы башлангыч партоешманың отчет-сайлау җыелышы зур активлык белән үтте.

Отчет чорында партия оешмасы шактый үскән, ВКП(б) членлыгына кандидат итеп 11 кеше кабул ителгән. Иптәш Мәкәр Әхметова үткән сайлаулар вактында партиясез иде. Ул хәзер ВКП(б) члены, МТС та алдынгы механиклардан берсе. Отчет чоры эчендә үсеп чыккан большевистик кадрлар МТС та күп кенә саналалар. Элекке комбайнчы иптәш Хәбибов хәзер МТС директоры урынбасары итеп, Ибраһимов МТМ мөдире итеп күтәрелде.

Фикер алышуларда чыгып сөйләүчеләр партоешманың эшендәге уңышларны күрсәтү белән бергә, аның кимчелекләрен большевистик тәнкыйть уты астына алдылар. Тракторларга һәм авыл хуҗалыгы машиналарына ремонт эше әле дә төгәлләнмәгән.

— Алдынгы тракторчылар һәм хатын-кызлар исәбенә партоешманың үсеше канәгатләнерлек түгел. Отчет чорында партия сафларына хатын-кызлардан бер генә иптәш кабул ителгән. Коммунистлар үзләренең политик белемнәрен күтәрү белән тиешенчә шөгыльләнмиләр. Күпчелек коммунистлар „ВКП(б) тарихының кыскача курсы“ның II нче һәм III нче бүлекләрен генә өйрәнәләр әле. Партия тарихын үзлекләреннән өйрәнүчеләргә җитәрлек ярдәм оештырылмаган.

Фикер алышуларда барлыгы 11 кеше сөйләде.

Аннары, җыелыш 3 кешедән партбюро сайлады.

З. Салахеттинов.

Доклад язылганны көтеп утырдылар

Норлат район советы башкарма комитеты янындагы башлангыч партоешманың отчет-сайлау җыелышы кич 7 сәгаткә билгеләнгән иде. Коммунистлар җыелышка вактында килделәр. Ләкин секретарь иптәш Игнатьевның язма отчеты хәзер түгел иде. Отчет язылып беткәнне сәгат ярым көтеп утырырга туры килде.

Отчетка „хәзерлекнең“ нәтиҗәсе бик тиз күренде. Иптәш Игнатьев партия оешмасының эше турында яхшылап бер сүз дә әйтә алмады.

Фикер алышуларда чыгып сөйләүче иптәш Николаев оешма секретаренең җыелышларны еш кына өзүе турында сөйләде. План буенча билгеләнгән 36 җыелыш урнына бары 19 гына үткәрелгән. Яңа кабул ителүчеләр арасында бер төрле дә эш алып барылмаган.

Иптәш Галиева партпоручениеләрнең үтәлеше тикшерелмәү турында әйтте. Ул болай диде:

— Мин комсомол оешмасы секретаре булып эшләдем. Ләкин беркетелгән коммунистларның берсе дә миңа ярдәм итмәде.

Җыелыш башлангыч оешманың эшен канәгатләнмәслек дип тапты.

Бу җыелыш, Норлат райкомының сайлауларга начар хәзерләнгәнлеген күрсәтте.

(ТатТАСС)

ЭШ КАНӘГАТЛӘНМӘСЛЕК ТАБЫЛДЫ

3 нче номерлы икмәк заводы шушы елларда гына салынган яңа предприятиеләрнең берсе. Производство планын сан һәм сыйфат ягыннан үтәү һәм арттырып үтәү өчен заводның бөтен мөмкинлекләре бар. Завод техникага һәм сәләтле кадрларга бай.

Шуңа карамастан, заводта производство планының сыйфат күрсәткечләре бик түбән әле. 12 шәр тонна икмәк бөтенләй бракка чыгарылу һәм хуҗасызлык фактлары да юк түгел.

Заводның шундый хәлдә булуының төп сәбәбе—эшчеләр арасында политик - масса эшнең тиешенчә оештырылмавында. Бригадалар арасында социалистик ярыш договорлары төзелсә дә, эшчеләр арасында индивидуаль ярыш оештырылмаган. Стена газеталары чыгарылмый. Техника түгәрәгенең эше ныклы юлга куелмаган.

Заводның җитәкчеләре „без яңа кешеләр, бездә кеше дә аз“ дип үзләренең җитешсезлекләрен акларга маташалар. Бу хәл 16 нчы февральдә булып үткән партоешманың отчет-сайлау җыелышында ачык күренде. Партоешма секретаре иптәш Коган докладта кимчелекләрне санап чыгу белән генә чикләнде. Ул кимчелекләргә тулы һәм политик анализ ясап, аларны бетерү юлларын күрсәтәсе урында, „без яңа кешеләр“ дип тынычланды. Завод директоры иптәш Мокеев та шуннан артык нәрсә әйтә алмады.

Членнары аз булган партоешмаларга ВКП(б) ның Молотов райкомы тарафыннан практик ярдәмнең тиешенчә күрсәтелмәве бу җыелышта да ачык күренде. Партоешманы үстерү өчен заводта мөмкинлекләр бар. Комсомол членнарын һәм заводның эшчеләрен политик яктан тәрбияләү эшен көчәйтергә генә кирәк.

Отчет-сайлау җыелышы партоешманың үткән чордагы эшен канәгатләнмәслек дип тапты.

Рим Баһау.

Зур активлык

Казан Юридик институты янындагы башлангыч партоешманың отчет - сайлау җыелышында партбюро секретаре иптәш Левшинның докладын тыңланды. Отчет чоры эчендә ВКП(б) сафларына институтның алдынгы укучыларыннан 58 кеше кабул ителгән. Партия сафларына кабул ителгән кандидатлардан Мингалиев, Кузнецов, Софранов, Якупов һ. б. иптәшләр фәкать отлично билгесенә генә укыйлар һәм җәмәгать эшләрендә актив катнашалар. Партия сафына кабул ителгәннәр белән эшләү өлкәсендә дә шактый нәтиҗәләргә ирешелгән. Оешма политик - масса эшләрен яхшыртуда зур гына эшләр башкарган. Бу чорда институтның студентлары һәм хезмәткәрләре арасында шулай ук җирле Советларга сайлаулар вактында йорт хозяйкалары арасында меннән артык беседа һәм докладлар үткәрелгән. 1938—1939 нчы уку елында һәм 1939—40 нчы уку елының беренче яртысында институт буенча уку планын тулы үтәүне тәэмин итүдә партия оешмасының роле зур булды. Отчет чорында коммунистларның укуда алдынгы сафта (авангард) баруга ирешүләре дә партия оешмасының уңышлы ягын күрсәтә.

Ләкин уңышлар белән бер рәттән, партоешма эшендә җидди генә кимчелекләр барлыгын да әйтергә кирәк. Бу кимчелекләр, барыннан да элек, оешманың акрын үсүеннән, яшь коммунистлар арасында „ВКП(б) ның кыскача курсы“н үзләштерүне тиешенчә оештырмаудан, бу өлкәдә коммунистлар өстеннән контроль булдырмаудан, комсомол оешмасына һәм оборона - масса эшләренә тиешенчә җитәкчелек итмәүдән, җирле советларга сайлаулар кампаниясе чорында массовый - агитация эшләре алып бару буенча тупланган бай тәҗрибәләрнең ныгытылмавыннан гыйбарәт.

Доклад буенча фикер алышуларда коммунистлар бик актив катнаштылар. Отчет доклады буенча барлыгы 16 коммунист чыгып сөйләде. Чыгып сөйләүчеләрдән Мостафин, Камский, Степанова, Владимиров, Курбатов һ. б. иптәшләр партоешманың практик эшендә булган җитешсезлекләрне күрсәттеләр һәм тәнкыйтьләделәр. Бигрәк тә ОСО, МОПР, медсестралар мәктәбе шикелле ирекле оешмаларның эшенә партбюроның җитәрлек әһәмият бирмәвен әйттеләр. Һәм җитешсезлекләрне бетерү буенча конкрет такдимнәр ясадылар.

Отчет - сайлау җыелышы, партоешманың политик линиясе дөрес, практик эшен канәгатләнерлек дип тапты. *Ж. Коновалов.*

КЫЗЫЛ АРМИЯНЕ ЛЕНИН ҺӘМ СТАЛИН ТӘРБИЯЛӘП ҮСТЕРДЕ

Полковник Н. БУШМАНОВ

Ленин—Сталин партиясе үзенең яши башлавының беренче көннәреннән үк, самодержавиегә каршы кораллы восстание хәзерләгәндә, пролетариатның сугышчан көчләрен туплау өчен агитация һәм оештыру эше алып барды. Большевиклар фабрикаларда һәм заводларда 5—10 кешелек кечкенә отрядлардан һәм дружиналардан сугышчан оешмалар төзеделәр. Бу дружиналарны ничек төзергә һәм өйрәтергә кирәклек турында инструкцияләрне Ленин үзе язды. Октябрь революциясенең „генераль репетициясе“ булган 1905—1907 нче елгы революциядә эшчеләрнең коралланган дружиналары беренче сугышчан чыныгу, беренче сугышчан тәҗрибә алдылар.

Ленин—Сталин партиясе тәрбияләгән эшчеләр дружиналары эшчеләр гвардиясенең, пролетариатның кораллы көченең нигезе булып әверелделәр. 1917 нче елның мартында сөргеннән кайткач иптәш Сталин эшчеләр гвардиясен оештыруга турыдан-туры кереште.

Барлык промышленность үзәкләрендә һәм шәһәрләрдә большевиклар эшчеләр гвардиясе отрядлары төзиләр. Озак та үтми, бу отрядларга Кызыл гвардия отрядлары исеме бирелә. Октябрь кораллы восстаниесе алдыннан Петроградның үзендә генә дә кызыл гвардеецлар 12 меңнән артык, Москвада 20 мең булды. Уралда, Донбасста, Иваново-Вознесенскида һәм башка үзәкләрдә дә кызыл гвардияне төзү эше шундый ук уңышлар белән барды.

1917 нче елның 10 нчы октябрендә большевиклар партиясе Үзәк Комитеты кичекмәстән кораллы восстание ясау турында Ленинның такдимен кабул итте. 16 нчы октябрьдә иптәш Сталин җитәкчелегендә Свердлов һәм Дзержинский иптәшләрнең катнашы белән восстаниегә җитәкчелек итү буенча Партия үзәге төзелде. Кораллы восстание планында В. И. Ленин төп кораллы көч сыйфатында иң зур игтибарны Кызыл гвардиягә юнәлдерә. Кызыл гвардия тирәсенә иске армиянең революцион настроениедәге солдатлары һәм матрослары берләшәләр.

Бөек Октябрь Социалистик революциясе җиңде. Ләкин буржуазия үзенең җиңелүе белән килешмәде. Ул Советлар властена каршы көрәшү өчен һәр җирдә контрреволюцион отрядлар оештырды. Кызыл гвардия алдына яңа бурыч—Октябрьнең казанышларын саклап калу бурычы килеп баса. Берничә ай эчендә Кызыл гвардия бөтен илдәге контрреволюцион учакларны тар-мар итте.

Ләкин озак та үтми, Советлар властен буу өчен, Россияне үзләренең колонияләренә әйләндерү өчен капиталистик илләрдәге империалистлар, Россиянең җимерелгән буржуазиясенә ярдәмгә ашыктылар. 1917 нче елның декабрендә Антанта вәкилләре Россиягә гаскәрләр җибәрергә, тар-мар ителгән рус ак гвардеецлары калдыкларына материаль ярдәм күрсәтергә карар бирделәр. Эчке һәм халыкара контрреволюция көчләре берләшәләр.

Берләшкән интервентларны һәм ак гвардеецларны тар-мар итү өчен Кызыл гвардиянең көчләре җитмәячәген, Совет республикасына көчле регуляр армия кирәклекне Ленин һәм Сталин күрделәр.

1918 нче елның 28 нче январенда В. И. Ленин Эшче-Крестьян Кызыл Армиясе оештыру турындагы декретка кул куйды. 14 нче февральдә Кызыл Хәрби Диңгез Флоты оештыру турында Совнарком карары иглан ителде.

Ленин—Сталин партиясенә, совет халкына үзенең Кызыл Армиясен гадәттән тыш авыр шартларда төзергә туры килде. Үзебезнең команда составы булмады, армияне төзү буенча оештыру эшләре үткәрергә сәләтле булган хәрби-административ аппарат булмады. Кораллар һәм сугыш кирәк-яраклары җитешмәде. Ә дошман—баштан-аяк коралланган халыкара империализм — капка төбендә генә тора иде.

Партиянең VIII нче съездында В. И. Ленин болай диде:

„Кызыл Армия төзү турындагы мәсьәлә бөтенләй яңа мәсьәлә иде, аның хәтта теоретик яктан да һич тә куелганы булмады. Без еш кына кармаланып барырга тиеш булдык“ (Ленин. Әсәрләр, XXIV нче том, 121 нче бит).

Ленин һәм Сталин Кызыл Армияне төзү буенча кызу рәвештә эшләп, дошманның өстен көчләренә каршы сугышудан хәзергә тыелып торырга һәм үзебезнең куәтле регуляр армиябезне төзү өчен тын алырга карар бирделәр. Халыкның явыз дошманы Троцкий, битлек киеп һәм хиянәт итеп, Германиягә каршы сугышырга котырта. Халык дошманнары Германия империалистлары кулы белән Совет республикасын буарга теләделәр.

Хезмәт ияләрен Кызыл Армия сафларына керергә чакырып 23 нче февральдә Совнарком өндәмә басып чыгарды. Ленинградның, Москваның һәм Совет республикасының башка шәһәрләренең ун меңнәрчә пролетарилары үз Ватаннарын саклау юлына басалар. 23 нче февраль Эшче-крестьян Кызыл Армиясенең һәр елны үткәрелә торган, бүгенге көндә бөтен совет халкы аңа зур шатлык белән хәзерләнә торган традицион бәйрәме булып әверелә.

Кызыл Армияне оештыруның беренче чорында ул иреклелек нигезендә тупланды.

1918 нче елның 10 нчы апреленә инде Кызыл Армия сафларында 198 мең 670 кеше, ә тагын бер айдан 306 мең 60 кеше була.

Большевиклар партиясе Кызыл Армия частьләренә җитәкчелек эшенә үзенең иң яхшы улларын—Фрунзене, Ворошиловны, Буденныйны, Щаденконы күтәрде, кызыл гвардеец эшчеләр арасыннан Чапаев, Щорс, Пархоменко, Котовский, Лазо кебек күп кенә халык арасыннан күтәрелеп чыккан геройларны тәрбияләп үстерде. Рядовой сугышчылардан һәм түбәнге комсостав арасыннан командирлар билгеләү белән бер рәттән Кызыл Армиядә эшләү өчен иске армиянең хәрби белгечләре дә тартылды.

Большевиклар партиясе тарафыннан кызыл командирлар хәзерләү өчен төзелгән кыска сроклы курслар, хәрби мәктәпләр һәм академияләр команда кадрларын тәрбияләүдә гаять зур роль уйнадылар.

Команда составын оештыру һәм тәрбияләү белән бер үк вакытта Ленин һәм Сталин Кызыл Армиянең партия - политик аппаратын төзеделәр. Полкларда полк һәм батальон коммунистик ячейкалары, партия бюролары һәм хәрби комиссарлар җитәкчелегендә эшләүче культура-агарту комиссияләре төзелә.

Ленин һәм Сталин хәрби комиссарларга аеруча әһәмият бирәләр. Иптәш Сталин тарафыннан военкомнарга карата төзелгән инструкциядә, хәрби комиссар армиядә Совет властеның һәм партиянең вәкиле һәм шунлыктан ул, сугышчыларны революция эшенә бирелгәнлек рухында тәрбияләп, полкның җаны һәм йөрәге булырга тиеш дип язылган.

Ленин: „Военком булмаганда бездә Кызыл Армия булмаган булыр иде“ диде. Кызыл Армиянең партия-политик аппараты—аның сугышчан куәтенең җимерелмәслек нигезе.

Кызыл Армиягә үзенең яши башлавының беренче адымнарыннан ук интервентларга һәм ак гвардеецларга каршы каты көрәш алып барырга туры килде. 1918 нче елның язында интервентлар Владивостокта, Архангельскида, Одессада, Николаевта, Закавказьеда һәм Төркстанда үзләренең гаскәрләрен төшерделәр. Совет властена каршы көрәштә үзәк рададагы хыянәтчеләргә ярдәм итү өчен чит ил империалистларының армияләре Украинага һәм Белоруссиягә китерелделәр. Волга буенда һәм бөтен Себер тимер юлы буенда чехословаклар корпусы Советларга каршы баш күтәрде.

Халыкара империализмның булышлыгы белән ак гвардеецларның контрреволюцион көчләре оештырыла: Уралда—атаман Дутов, Волга буенда—ак гвардияче „халык армиясе“, көнчыгышта—Уфа директориясе армиясе һәм Себер вакытлы хөкүмәте армиясе, Донда—атаман Краснов һәм Кубаньда генерал Деникин. 1918 нче елның җәендә утлы фронтлар боҗрасы Совет республикасын чолгап алды.

Хәлнең җиддилеген аңлап, Совет хөкүмәте 1918 нче елның 29 нчы маенда Кызыл Армияне иреклелек нигезендә туплау принципыннан эшчеләргә һәм ярлы крестьяннарга гомуми мобилизация ясауга күчү турында карар чыгара. Ленин—Сталин партиясе партия членнарын гомуми хәрби өйрәтүне кертә һәм үзенең иң яхшы улларын армиягә җибәрә. 1918 нче елның җәендә иптәш Сталин Царицын районында ак гвардеецларны тар-мар итүне оештырып, үзенең хәрби эшен башлады. Партия Кызыл Армияне ныгыта. Аерым полклар һәм отрядлар дивизияләргә, армияләргә һәм фронтларга тупланалар.

1918 нче елның көзенә Кызыл Армияне оештыру нигездә төгәлләнде.

30 нчы ноябрьдә большевиклар партиясе Үзәк Комитеты һәм хөкүмәт Ленин җитәкчелегендә эшче һәм крестьян оборона советы төзеделәр. Бу советның составына иптәш Сталин керде.

Гражданнар сугышы торган саен кабына барды. Империалистлар үзләренең күп меңле армияләрен оештырдылар, аларны коралландырдылар һәм Совет республикасына каршы җибәрделәр. 1918 нче елның октябрендә В. И. Ленин Бөтенроссия Үзәк Башкарма Комитеты утырышына язган хатында болай диде: „Социализмны саклау өчен барлык корбаннарга барырга хәзер торучы эшчеләрнең һәм ярлы крестьяннарнең Кызыл Армиясе төзелә. Чехсловакларга һәм ак гвардеецларга каршы сугышларда армия ныгый һәм чыныга. Нигез нык салынды, бинаның үзен салуны ашыктырырга кирәк. Без язга 1.000.000 кешелек армия булдырырга карар биргән идек, хәзер безгә өч миллион кешелек армия кирәк. Без аны булдыра алабыз. Без аны булдырырбыз“ (Ленин. Әсәрләр, XXIII нче том, 217 нче бит).

Юлбашчының күрсәтмәсе тиз һәм тулысынча тормышка ашырыла. Ленин—Сталинның сыналган җитәкчелегендә Кызыл Армия Царицын янында Красновның ак казаклар армиясен тар-мар итә. Көнчыгыш фронтында колчакчыларны кыйный. Троцкийның һәм аның иярченнәренең армияне һәм фронтны идарә итүдәге хиянәтчел эшләре нәтиҗәсендә Көнчыгыш фронтында туган һәлакәтле хәлне бетергәндә, иптәш Сталин Кызыл Армиягә классик оператив осталык принципларын бирде. Пермь һәлакәтенең сәбәпләрен тикшергәндә һәм ул һәлакәтне бетергәндә, иптәш Сталин Кызыл Армияне һәм аның тылын халык дошманнарының чит һәм дошман элементлар белән чүпләргә маташуларын фаш итте һәм кисте.

(Дәвамы киләсе номерда).

ЯЗГЫ ЧӘЧҮГӘ ХӘЗЕРЛЕК



Балык Бистәсе районының „Авангард“ колхозы членнарыннан М. Воробьева һәм Р. Павлова иптәшләр триерда орлык чистарталар.
Л. Попов фотосы
(ТатТАСС фотохроникасы).

ХӘЗЕРЛЕК ЯХШЫРА

Авыл хуҗалыгы алдынгыларының республика киңәшмәсе мөраҗәгатен өйрәнеп, аны тормышка ашыру буенча практик чаралар күрү нәтиҗәсендә, Чепья районы, Фрунзе исемендәге колхозда язгы чәчүгә хәзерлек яхшырды. Чәчү өчен кирәк булган орлыкны җитәрлек туплады, аны яраклы кондициягә җиткерде. Машиналарга һәм транспорт инвентарена ремонт ясауны 10 нчы февральгә тәгәлләде. Ремонт ясалган барлык машиналар комиссия тарафыннан тикшерелеп яхшы билгесенә кабул ителде.

Колхоз кар тоту, көл, фикаль җыю планын тулысынча үтәде. Басуга тирес чыгару да уңышлы бара. Еллык планның 65 проценты үтәлгән инде. Яз көне туфракка кертеләчәк минераль ашлама колхозга ташып куелган.

Колхозчылар арасында хезмәт дисциплинасы яхшы. Язгы чәчүгә хәзерлек буенча эшләүче колхозчылардан Галимҗанова, Шакиров һәм башка күп кенә иптәшләр көнлек норманы системалы рәвештә арттырып үтиләр.

Колхозда агротехниканы өйрәнү түгәрәге оештырылган. Түгәрәк эшенә колхозның агротехнигы иптәш Зәйнуллин җитәкчелек итә. Ул биш тапкыр занятие үткәргән инде.

Бу колхоз „КИМ“ колхозы белән ярыша. Шушы көннәрдә ярыш договорының үтәлешен тикшерү өчен „КИМ“ колхозы делегациясе Фрунзе исемендәге колхозда булды. Комиссия колхозның язгы чәчүгә хәзерлеген яхшы дип тапты.

Авыл хуҗалыгы алдынгыларының республика киңәшмәсе делегаты иптәш Галләмов җитәкчелек итә торган „Кызыл яр“ колхозы да язгы чәчүгә хәзерлекне тәгәлләп килә. Колхозда чәчү орлыкларын чистарту, басуга тирес чыгару, кар тоту планнары тулысынча үтәлгән. Колхозның атлары көр һәм таза.

Х. Галләмов.

ЙӨКЛӘМӘЛӘР ҺӘМ ЧЫНБАРЛЫК

Быел югары иген уңышын яулап алу өчен Биләр һәм Алексеевский районнары үзара социалистик ярыш договорлары төзегәннәр иде. Ярыш договорының үтәлешен тикшерү буенча Биләр районы делегациясе Алексеевский районында булды һәм райондагы ике МТС та һәм биш колхозда язгы чәчүгә хәзерлек эшләрен тикшерде.

Делегация „Мысль Ленина“ колхозының эш тәҗрибәләре белән аеруча нык кызыксынды. Бу колхозда язгы чәчүгә хәзерлек эшләре яхшы. Кар тоту планы 100 процентка үтәлгән. Язгы чәчү өчен кирәкле орлык, саклык фонды һәм фураж тулысынча хәзерләнгән. Басуга тирес чыгару буенча еллык план 50 процент үтәлгән. Машиналарга, инвентарьларга ремонт эшләре дә яхшы бара. Колхозда терлекләрне тәрбияләүгә нык әһәмият бирелә. Терлекләрнең көрлеге яхшы.

Делегация Алексеевский районының күп кенә колхозларында язгы чәчүгә хәзерлек буенча зур җитешсезлекләрне дә ачты. Мәсәлән, „Кама“ колхозы җитәкчеләре күз буяучылык белән шөгыльләнгәннәр. Кар тоту бөтенләй үткәрелмәгән. Ә алар 280 га мәйданда кар тоту үткәрелде, дип район җир бүлегенә ялган мәглүмат биргәннәр. Ремонтның да сыйфаты начар. Колхозда хезмәт дисциплинасы йомшак. Хезмәт көнәре минимумын үтәмәгән 124 кеше бар. Аларның 45 е бер генә хезмәт көне дә эшләмәгәннәр. Аларга карата һичбер чара күрелмәгән.

„Восход“, „Красное Прикамье“, „Ясная Поляна“ колхозларында орлыкларны чистарту эше оештырылмаган. Кышкы агротехника чараларын үткәрү планы бригадаларга җиткерелмәгән. Бу колхозларда басуга тирес чыгару эшләре бик начар бара. Соңгы ике колхозда көл, кош тизәге, фикаль ашламалар җыю һәм компас хәзерләү эшләре башланмаган да. Терлекләрне тәрбияләүгә әһәмият бирелми. Терлек азыгын әрәм-шәрәм итәләр.

Алексеевский МТС ында 10 нчы февральгә тракторга ремонт ясау планы 43,2 процентка гына үтәлгән. Ремонтланган тракторларның күп кенә частьләре җитешми. Ремонтның сыйфаты начар.

Район җир бүлеге колхозларда агротехника укулары оештыру эшләре белән бөтенләй шөгыльләнми. Агротехниканы өйрәнү буенча районда бары 8 түгәрәк эшли һәм аларда 120 кеше укый. Механизатор кадрлар хәзерләү белән дә шундый ук хәл.

Алексеевский районының партия, совет оешмалары ярыш договоры шартларын тулысынча үтәү өчен большевистик көрәш оештырырга тиешләр.

Б. Михайлов.

МТС ларда тракторларга ремонт ясауның барышы турында Татарстан Җир Эшләре Халык Комиссариаты сводкасы

1940 нчы елның 15 нче февраленә

Көзге-кышкы ремонт планына карата процентларда

МТС лар	Үтәлеш	МТС лар	Үтәлеш	МТС лар	Үтәлеш
Нөркәй	100,0	Алабуга	80,0	Юдино	44,7
Тымытык	100,0	Буденный	60,0	Иске Писмән	44,4
Кама Тамагы	100,0	Тәтеш	59,6	Тат. Ялтан	44,4
Маткавыш	100,0	Тәкәнеш	59,5	Буа	44,2
Актаныш	100,0	Саба	59,1	Салман	44,1
Мөслим	10 ,0	Каргалы	57,1	Чыбыклы	43,2
Яниль	100,0	Чишмә	5 ,7	Алексеевский	43,2
Чаллы	100,0	Балык бистәсе	56,2	Поповка	42,9
Теләче	100,0	Кукмара	55,3	Питрәч	42,7
Черемуховский	92,9	Акташ	53,7	Биляр	42,6
Юртыш	92,0	Базарлы Матак	53,7	Әлки	42,0
Кадрәк	90,2	Вондюг	53,6	Кичү	40,7
Әлмәт	90,2	Кызыл Юл	52,5	Альши	40,6
Т. Тамак	88,6	Зур Кләре	52,1	Морт	40,4
Минзәлә	88,1	Калинин	51,9	Рождественский	39,6
Тирсә	87,0	Кузнечиха	51,9	Дөбъяз	38,9
Тархан	81,4	Зирекле	51,2	Кызыл Йолдыз	38,2
Зур Поляна	81,0	Иске Тимошкино	51,2	Баулы	37,5
Алга	77,8	Сокольский	51,1	Зәй	37,3
Сарман	75,9	Макыл	5 ,1	Үвәк	34,6
Иши	73,5	Балтач	50,9	Яна Чишмә	33,3
Столбище	72,7	Кошкино	50,0	Мөрәле	30,5
Дәүләки	72,5	Мәйдан	50,0	Димитров	30,3
Азин	71,8	Кәкре Елга	49,1	Тельман	30,0
Аксубай	71,4	Беренче Май	48,8	Чокалы	29,1
Мәлки	70,8	Арча	48,5	Константиновка	28,1
Иске Чишмә	68,2	Ютазы	48,1	Карамалы	24,5
Октябрь	67,9	Кузайкино	48,1	Татходяш	21,3
Чистай	65,0	Трехозерский	48,0	Зөя	12,8
Мамадыш	64,8	Норлат	47,8		
Шөгер	64,7	Ромадан	47,7	МТС лар буенча барлыгы	56,7
Чаллы	64,6	Әхмәмәт	47,7		
Кызыл Чапчак	61,0	Бөгелмә	46,6	1940 нчы елның 10 нчы февраленә	54,5
Куйбышев	64,0	Чурибураш	46,5	1939 нчы елның 15 нче февраленә	58,8
Чүпрәле	61,0	Мөслим (Чистай)	45,8		
Исәнбай	60,5	Биектау	45,3		
Әтнә	60,0	Чиябаш	45,1		

Гаеп атта да, тәртәдә дә бар...

Татнаркомземның бер яхшы ягы бар. Яхшыны яман дип булмый. Ул ел саен „Басу культуралары буенча агротехник күрсәтмәләр“ бастырып тарата. Заказны, билгеле Татгосиздат үти. Ләкин бу бик кирәкле кулланманы ел саен ике-өч айга соңга калып чыгару гадәт булып киткән. 1939 нчы ел өчен кулланма март азакларында гына бастырып таратылган.

1940 нчы елга карата булган бу әсәрнең кайчан басылып чыгуы мәглүм түгел әле. „Агротехник күрсәтмәләр“ быел вактында язылган булса кирәк. Аның авторларыннан берсе иптәш Г. Р. Прохоров: күрсәтмәләрнең кульязмасы 31 нче декабрьдә үк нарком иптәш Черзор кулына тапшырылган иде, ди. Ләкин агротехника һәм механизация управлениесенең начальнигы да, бу әсәрнең авторы да булган иптәш Прохоровка кульязманың кулдан ычкынуы белән, „инде котылдым“ дип тынычланмаска кирәк иде.

— Брошюра бездән китте, Татгосиздатның авыл хуҗалыгы секторының мөдире иптәш Кадыйров басып чыгаруны ашыктырырга тиеш ди иптәш Прохоров.

Һич каршы килмибез, тиеш, бик тиеш!

Ләкин Татгосиздатта да ул кадәр бик ашыгырга исәпләмиләр әле. Әллә Наркомземда булган шикелле сәбәпләр Татгосиздатта юкмы?

— Рус телендә чыгачак җиде табаклы „Агротехник күрсәтмәләр“ не басар өчен... ике табагына гына кул куелды әле, ди мөдир иптәш Кадыйров.

Шуннан соң үзеннән үзе:

— Ни өчен? дигән сорау туа.

Җавап хәзер:

— Безгә соң бирделәр. Аннан соң, беренче ике табакка инде 110 төзәтмә дә кертергә өлгерделәр: 55 сүзне алып ташладылар, 55 не керттеләр. Менә шуннан үзен уйлап кара инде, диләр.

Әйе, шулай. Колхозчылар инде күптәннән бирле кышкы агротехника чаралары алып баралар. Кар тоталар. Тирес, көл җыялар, өяләр, ташыйлар... Матур, җылы кояш карый башлар. Тоткан карлар тиздән эрерләр, аккан сулардан дәрьялар хасил була башлар. Тиресләрне, көлләрне басуларга тарата башларлар...

Наркомзем белән Татгосиздатта каләм шытырдатып утырганчы, брошюраны корректировать иткәнче кыш та үтәр, яз да җитәр, чәчүгә дә чыгарлар.

Брошюраны чыгару өчен икесе дә борчылмый. Гаеп атта да, тәртәдә дә бар. Аты кем дә, тәртәсе кем булуны укучы үзе белер инде.

Ф. Балыкчы.

ХАЛЫК УТЫРЫШЧЫЛАРЫ ҺӘМ АЛАР БЕЛӘН ЭШЛӘҮ

ССР Союзының, Союзный һәм автономияле республикаларның суд төзелеше турында законның 12 нче статьясендә,... судта үзләренең хезмәтләрен үтәгән вакытта халык утырышчылары судьянең барлык хокуклары белән файдаланалар, диелә, ә 19 нчы статьяда... халык судьясе вакытлыча булмаганда (авырганда, отпускыда чагында һ. б.), судья хезмәтләрен үтәү хезмәт ияләре депутатларының район Советы тарафыннан халык утырышчыларының берсенә йөкләнә, дип күрсәтелә. Бу бөек бурычларны уңышлы рәвештә тормышка ашыру һәм халык судына керә торган эшләрне дөрес хәл итә белү өчен, халык утырышчысы политик һәм юридик яктан белеме булырга тиеш. Халык судлары халык утырышчыларының эшенә системалы рәвештә җитәкчелек итәргә, алар белән программа буенча занятиеләр үткәрергә һәм аларга белем бирергә тиешләр.

Халык утырышчыларына җитәкчелек итү буенча халык судьяләре эшенә ясалган тикшерүләрнең йомгаклары һәм 1939 нчы елны халык судьяләре отпускыда булган вакытта судья хезмәтен үтәгән халык утырышчылары тарафыннан алып барылган эш яхшы нәтиҗәләр бирде.

Хезмәт ияләре депутатларының район Советлары халык судьяләре хезмәтен үтәү өчен халык утырышчыларыннан 229 кешене раслаган иде. Аларның 9 проценты эшчеләр, 26 проценты колхозчылар һәм 65 проценты хезмәткәрләр. 1939 нчы елның июнь-сентябрь айларында 59 суд участкысында халык утырышчылары халык судьяләре хезмәтен вакытлыча үтәделәр. Халык судьяләре алар белән занятиеләр, беседалар үткәрделәр, аларны материаль һәм процессуаль законнарның төп положениеләре белән таныштырдылар, аларны куллану, приговорлар һәм карарлар чыгару, приговорларны һәм карарларны үтәү тәртипләрен аларга аңлаттылар.

Арча МТС ы стахановчыларыннан планнарын 200—300 процентка үтәүче токарь Б. Алексеев (сулда) һәм слесарь И. Носов иптәшләр.
А. Михайлов фотосы
(ТатТАСС фотохроникасы).

Халык утырышчылары яхшы эш үрнәкләре күрсәттеләр, суд органнарына йөкләтелгән бурычларны нигездә дөрес аңладылар һәм законнарга яхшы төшенделәр.

Иптәш Н. Х. Ибатуллин хезмәт ияләре депутатларының Сталин район Советы президиумы тарафыннан расланган иде һәм ул Казан шәһәренең 11 нче участкы халык судьясе иптәш Федорова отпускыда булган вакытта, халык судьясе хезмәтен үтәде. 10 нчы августтан 10 нчы сентябрьгә кадәр 109 эшне карады. Ул суд процессын культуралы итеп алып барды, якларның процессуаль хокукларын бозуга юл куймады, сорауларны уйлап, ачык һәм дөрес бирде. Приговорларны һәм карарларны дөрес язды.

Иптәш Некрасов 10 нчы июльдән башлап 3 ай буена Казан шәһәренең 19 нчы участкысында судья хезмәтен үтәде. Шушы вакыт эчендә ул 466 эш карады. Иптәш Некрасов процессуаль һәм материаль законнар белән яхшы таныш, приговорларны һәм карарларны грамоталы яза.

Болар рәтенә халык утырышчысы Ландышева (Казан, 13 нче участкы), Русаков (Казан, 6 нчы участкы), Корнеев (Ширәмәт районы) иптәшләрне кертергә була.

Бу эшкә җитәкчелек итүдә җитешсезлекләр дә бар әле. Кайбер халык судлары халык утырышчыларын судларның көндәлек эшләре белән җитәрлек дәрәҗәдә таныштырмаганнар.

Мәсәлән, Казан шәһәренең 9 нчы участкы халык судьясе иптәш Шебаршев, чираттагы отпускыга китәргә җыенгач үз урнына бөтенләй хәзерлеге булмаган утырышчы иптәш М. Тимербулатовны калдырган, аны суд процессын алып бару, приговорларны һәм карарларны язу тәртипләре белән, суд канцеляриясенең эше белән таныштырмаган. Аңа бик күп санда каралмаган эшләр калдырган.

Халык судларының башка кайбер участкыларыннан да шундый фактларны китереп була. Бу фактлар халык утырышчылары белән эшнең әле җитәрлек булмавын күрсәтәләр. Бу җитешсезлекләр бетерелергә тиеш. Халык утырышчыларын партиябезнең һәм хөкүмәтебезнең директивалары белән, законнар белән, суд процессларын алып бару техникасы, приговорлар һәм карарлар чыгару тәртибе белән системалы рәвештә таныштырып торырга кирәк. Шул вакытта гына халык утырышчылары үзләренә күрсәтелгән ышанычны аклый алырлар, үзләре алдында торган бурычларны уңышлы рәвештә башкара алырлар.

Галимов.

ТАССР Юстиция наркоматының өлкән консультанты.

ДАНЛЫКЛЫ 30 ЕЛ

(Шәриф Камалның әдәби-иҗтимагый эшчәнлегенә 30 ел тулу көненә)

Татар совет әдәбияты классигы, атаклы язучы Шәриф Камалның әдәби һәм иҗтимагый эшчәнлегенә 30 ел тулды. Моннан 30 ел элек эшчеләр тормышыннан алып язылган кыска-кыска хикәяләре белән татар матбугатына килеп чыккан Шәриф Камал, революциягә кадәр демократик татар әдәбиятының, Октябрь Социалистик Революциясеннән соң татар совет әдәбиятының иң алгы сафтагы күренекле вәкилләреннән берсе булды.

Революциягә кадәрге татар демократик әдәбияты халык шагыйре Габдулла Тукай, татар драматургиясенең атасы Галиәсгар Камал, изелүчеләр моңын җырлаучы шагыйрь Мәҗит Гафури, революционер әдип Гафур Колахмәт кебек эре художникларны эченә ала. Бу язучыларның барсы да диярлек 1905 нче елгы революция ялкыны белән күтәрелеп, шул чорның алдынгы, прогрессив идеяләрен гәүдәләндереп чыктылар.

1905 нче елгы революция бастырылганнан соң илдә көчле реакция башланды. Революция чорында халыклар көрәшеп алган барлы-юклы иркенлекләрне һәм хокукларны да тартып алып, реакция халыктан, аның революцион катлавыннан үч алырга керешә. Революцион карашлы кешеләрне аяусыз рәвештә асу-кисү башланды. Төрмәләр һәм каторгалар тоткыннар белән тулдылар. Столыпин реакциясе еллары эшчеләр сыйныфына жандармнарның һәм полицейскийларның, патша провокаторларының һәм җимерүче кара груһларның разбойникларча һөҗүм ясаулары белән бигрәк тә аерылып торды“ („ВКП(б) тарихының кыскача курсы“).

Бу хәл реакция елларында татар демократик язучылар катлавында ачы нәфрәт, тирән ачыну һәм вакты-вакты белән өметсезләнү тойгыларын тудырды. Г. Тукай, М. Гафури, Г. Камал кебек алдынгы язучылар реакция көчләрен тагын да кискенрәк формада фаш иттеләр. Сатлык милләтчеләрнең йөзләрен ачтылар, изелүче халыкның моң-зарын ачынып җырладылар.

Шәриф Камал әдәбиятка менә шул реакция елларында килде һәм югарыда саналган алдынгы эре демократик язучылар сафына көчле бер көрәшче булып басты. Ләкин Ш. Камал үзеннән элегерәк әдәбиятка килгән бу язучылар күтәргән мотивларны кабатлаучы гына булып калмады. Ул үзенең иҗады белән татар демократик әдәбиятының яңа тармагын чәчәкләндерде; ул бу әдәбиятка яңа бер агым (струя) алып килде. Бу яңалык аның әсәрләренең эчтәлегендә дә һәм формасында да урын алды.

Ш. Камал әсәрләрендәге яңалык, барыннан да элек, тематика яңалыгы була. Ш. Камалның беренче әсәре булган „Уяну“ да ук инде без аңа чаклы татар әдәбиятында сирәк чагылган эшче тормышын очратабыз. Ш. Камалның моннан соңгы күп кенә әсәрләре һәм „Козгыннар оясында“, „Акчарлаклар“ кебек атаклы классик повестьлары сезонлы эшчеләр, шахтерлар, тимер юлчылар тормышын гәүдәләндерделәр. Шулай итеп, Ш. Камал татар әдәбиятына эшчеләр тематикасын алып килде һәм шуны өзлексез дәвам иттерде.

Ш. Камал капитализм шартларында эшчеләрнең авыр тормышын ачынып сурәтләү белән бергә, ул эшчеләр средасындагы унай моментларны—коллективлык хисләрен, интернационал бердәмлек карашларын оста һәм ышандырырлык итеп бирде. Ш. Камалның, авыр эш шартларында бер кайгы, бер теләк белән, бер туган булып бер-берсенә үзләшкән эшче геройлары, дөньяга карашлары һәм тойгылары ягыннан яңа тип кешеләр. Алар мещаннарга, обывательләргә хас булган тар эгоистлык, карунлык, мал өчен җан сатарга хәзер торучанлык сыйфатларыннан азатлар. Аларда коллективчылык хисләре тәрбияләнә. Эшчеләр арасындагы интернационализм мотивы Ш. Камал иҗадында нык урын алды.

Болардан башка тагын Ш. Камал үзенең көчле сатирик әсәрләре белән татар буржуаз милләтчеләрен һәм руханиларын аяусыз фаш итте („Депутат“, „Сәмруг кош“, „Хаҗи әфәнде өйләнә“), обыватель, мещан идеологияләрен, кешелек хисләрен хурлаучы тупас карашларны ачып салды („Халера вактында“ һ. б.); хатын-кызларның элек тоткынлыкта, хокуксызлыкта яткырылуын гәүдәләндерде, шул хәлгә каршы көрәш алып барды („Сулган гөл“, „Нәфисә“ һ. б.). Болар барсы да Шәриф Камал иҗадының төп демократик юнәлешен күрсәтүче әсәрләр. Ш. Камал бу әсәрләре белән реакцион көчләрне, аяусыз эксплоатацияне фаш итеп, сатлык милләтче буржуаз интеллигенциянең битлеген җыртып, мещанлыкка, обывательчелек идеологиясенә каршы ут ачты. Халыкны яктыга, чын кешелек дөньясына өндәде.

1917 нче елгы Октябрь Социалистик Революциясенең җиңүе һәм илдә Советлар власте урнаштырылу Ш. Камалның демократик сызык белән үсеп барган иҗадына яңа көч бирделәр.

Революциядән соң ул коммунистлар партиясе сафына кереп (1919 ел), партиянең ялкынлы эшчесенә әйләнә. Бу елларда ул Оренбургта (хәзерге Чкалов), Төркстан фронты политбүлеге газетасында актив катнашып, Кызыл Армия сафларында политик-тәрбия эшен алып бара. Шулай итеп, революциянең беренче көннәреннән үк үзенең иҗтимагый эшчәнлеген революция белән бәйләде һәм партиянең актив члены була.

Ш. Камалның революциядән соңгы иҗады „Таң атканда“, „Матур туганда“ кебек зур күләмле романнар һәм дистәләгән пьесалар белән характерлы. Ш. Камалның бу әсәрләре үзләренең тематикалары һәм идея эчтәлекләре белән аның элекке иҗадыннан күп аерылалар. Ш. Камалның бу дәвер иҗадында совет тематикасы киң урын алды. Бу әсәрләре белән ул совет предприятиеләрендә социалистик төзелеш өчен барган көрәшне чагылдыра, социалистик төзелешнең дошманнарын фаш итә („Ут“); социалистик промышленностьның алдынгы энтузиаст стахановчыларын гәүдәләндерә („Томан арты“), авыл хуҗалыгын социалистик нигездә үзгәртеп кору өчен барган масса көрәшен һәм кулакларга каршы көрәшне чагылдыра („Матур туганда“).

Ш. Камалның 30 еллык иҗад юлы хезмәт иясе халкы белән нык бәйләнгән. Шәриф Камал иҗадының иң зур көче—аның халык белән нык бәйләнгән булуында.

Ш. Камал иҗадының көче—аның реалистлыгында. Ш. Камал татар әдәбиятында чын реализм мәктәбен тудыручыларның берсе. Капитализмны фаш итеп, изелүче халыкның аянычлы тормышын сурәтләп, аның киләчәгенә өмет һәм омтылыш тудыру—бары реализм аша гына мөмкин иде. Ш. Камал революциядән соңгы әсәрләрендә дә реализмны дәвам итеп һәм аны югары социалистик төскә күтәреп, безнең җәмгыятнең алга үсешен матур җанландырды.

Ш. Камал иҗадының көче—бөек рус халкы әдәбияты һәм башка халыклар әдәбиятыннан өйрәнүендә, аларның үрнәкләрен мисаль итүдә һәм үзе дә интернационал мотивларны эченә алган, бөтен СССР халыклары әдәбияты эченә керерлек җәүһәрләр иҗад итүендә. Ш. Камал бөек рус классиклары А. П. Чехов һәм М. Горькийдан өйрәнде. Алар үрнәге белән иҗад итте. Ш. Камал үз иҗадын бөтен кешелек көрәше мотивлары белән сугарып, аны күп телдәге совет әдәбиятының бер кисәге итә алды.

Ш. Камал иҗадының көче Ленин—Сталин партиясенең даһи күрсәтмәләрен әдәби чаралар аркылы гәүдәләндерүендә, бүгенге көннең алдынгы, актуаль проблемаларын бирүендә.

Ш. Камалның әдәби, иҗтимагый эшчәнлегенә 30 ел тулу уңае белән Татарстан хөкүмәте Ш. Камалның юбилеен үткәрергә карар чыгарды һәм Хөкүмәт Юбилей Комиссиясен төзеде. Бу юбилейгә бөтен хезмәт ияләре, язучылар, укучылар хәзерләнәләр. Бу юбилей татар совет әдәбиятының, татар совет культурасының бәйрәме булып узачак.

Бу бәйрәмгә Татарстан хезмәт ияләре генә түгел, СССР башкаласы Москваның язучылар җәмагатчелеге дә, күрше тугандаш республика халыклары да, шулай ук Чкалов, Горький өлкәләре хезмәт ияләре дә хәзерләнәләр. Бу факт бездә милли совет культурасының уңышы—совет культурасының тулаем уңышы булуын тагын бер кат раслый.

Ш. Камалның 30 еллык юбилеен уздыру шушы елның 15 нче февраленнән башланып, март ахрында булачак тантаналы кичә һәм Ш. Камал пьесасының юбилей постановкасы белән тәгәлләнә. Юбилей вактында юбилей комитеты һәм язучылар союзы эре предприятиеләргә һәм районнарга унлап язучылар бригадалары оештыра. Бу бригадалар урыннарда әдәби кичәләр, Ш. Камал иҗады турында докладлар, беседалар үткәрәләр. Клубларда, уку йортларында, китапханәләрдә Ш. Камал иҗады һәм совет әдәбияты темасына күргәзмәләр оештырыла.

Юбилей көннәрендә язучылар союзы правлениесе үзенең юбилей пленумын уздыра. Юбилей уңае белән Тел һәм Әдәбият институты һәм язучылар союзы күп кенә темага гыйльми тәнкыйть мәкаләләре оештырдылар. Бу хезмәтләр вакытлы матбугатта һәм аерым-аерым брошюра итеп басылып чыгачаклар.

Ш. Камалның 30 еллык юбилеен принципиаль югарылыкта күтәреп, аны зур иҗадның сокландыргыч тәҗрибәләрен туплау, аларны киң язучылар катлавына җиткерү, яңа зур иҗадка этәргеч итү чарасына әйләндерергә кирәк.

М. Җәлил.

ЧИТ ИЛЛӘРДӘ

КӨНБАТЫШ ЕВРОПА СУГЫШЫ

БЕРЛИН, 17 февраль. Германия армиясенең верховный командованиесе хәбәр итә: көнбатыш фронтта Варндт районында разведка операциясе вактында, Саарбрюкеннан көньяк-көнбатыштарак берничә француз плен алынган. Югары Рейн районындагы фронтта ике яктан да пулеметтан һәм мылтыктан атышу булган. Германия истребителе Төньяк диңгезе өстендә Англиянең Бристол-Бленгейм типындагы самолетын бәреп төшергән.

БРЮССЕЛЬ, 16 февраль. „Журналь“ газетасының хәрби күзәтүендә болай диелә: „Кар яуу патрульләрнең хәрәкәтен шактый киметте. 14 нче февральдә иртә белән немецләр Саардан көнчыгыштарак беренче тапкыр һөҗүм ясадылар. Көчле атуга очраган дошман чигенергә мәҗбүр булды. Төнлә Саардан көнбатышта операцияләр яңарды. Немецләр бик нык атышканнан соң чигенделәр. Диңгездә французлар немецләрнең бер сәүдә пароходын тотып үз портларының берсенә алып килделәр.

Англичаннар 9 нчы февральдән башлап Германиянең ике су асты көймәсен батырганлыкларын игълан иттеләр“.

ЛОНДОН, 17 февраль. Рейтер агентлыгының хәбәр итүенә караганда, дошман Англиянең 4.622 тонна авырлыгындагы „Ленглифорд“ пароходын батырган. Пароход командасының 15 кешесе көймәгә утырып Эйрегә килеп җиткән. Аларның берсе юлда үлгән. Команда членнары утырган икенче бер көймә хәбәрсез югалган.

Рейтер агентлыгының хәбәр итүенә караганда, Италиянең 5.694 тонна авырлыгындагы „Джорджио Ольсен“ исемле йөк пароходы Англиянең көнчыгыш яры буенда минага бәрелеп баткан. Командадагы 32 кешедән 17 кеше коткарылган.

Англиянең диңгез министрлеге 9 нчы февральдә баткан „Роберт Боуэн“ һәм „Форт Ройял“ траулерлары моряпларының исемлеген игълан иткән. Исемлектә 21 морякның, шул исәптән 4 офицерның исме бар.

Алынган мәгълүматларга караганда, Шотландия ярлары буена Норвегиянең ватылган пароходының кисәкләре килеп чыккан. Пароходның исмен белеп булмаган. Англиядән Норвегиягә киткән ике пароходның берсе—яки 1.000 тонна авырлыгындагы „Бисп“ пароходы, яки 1.168 тонна авырлыгындагы „Старт“ пароходы һәлак булгандыр дип уйлыйлар. „Бисп“ Англиядән 20 нче январьда, ә „Старт“ 29 нчы январьда киткән булган. Шул вакыттан бирле бу пароходлар турында бер нинди хәбәр булмаган. (ТАСС).

НОРВЕГИЯГӘ ГЕРМАНИЯ ПРОТЕСТЫ

БЕРЛИН, 17 февраль. (ТАСС). Германия информация бюросы түбәндәге рәсми белдерүне тапшыра:

„Кичә кич белән хәбәр ителгәнчә, Англиянең хәрби диңгез көчләре Норвегиянең нейтралитетын һич ишетелмәгән төстә боздылар. Англиянең сугыш караблары Норвегия суларында, яр буеннан 200 метр ераклыкта Германиянең коралсыз „Альтмарк“ пароходын тотып алырга маташтылар.

Англичаннар тарафыннан халыкара хокукны болай һич ишетелмәгән төстә тупас рәвештә бозу актын башта булдырмаска мөмкин булган булса, хәзерге вакытта Германиянең „Альтмарк“ пароходына яңа һөҗүм ясалу турында хәбәрләр алына. Англичаннарның бу пиратларча һөҗүме Англиянең хәрби флоты тарихында хурлыклы тап булып калыр.

23 сәгать 07 минутта Германиянең „Альтмарк“ пароходы капитаны Англия сугыш корабларының халыкара хокукны бозулары һәм Германиянең коралсыз сәүдә пароходы белән гафу ителмәслек могамәләдә булулары турында Германиянең Ослодагы илчелегенә радио буенча хәбәр итте. Германия пароходы Норвегиянең ике миноносы озатуында Иосинг фиордына качарга мәҗбүр булган. Капитан юлны дәвам иттерү өчен шунда ук көчле конвой таләп иткән. Германиянең Ослодагы илчелеге шунда ук Норвегиянең чит ил эшләре министрлеге белән элемтә урнаштырган. Норвегиянең чит ил эшләре министрлегенең дәүләт секретаре аңа Англия адмиралтействосының тынычландырырлык вәгъдәләр биргәнлеген белдергән. Үз тарафыннан Норвегиянең диңгез министрлеге дә „Альтмарк“ пароходының тиешле яклау алачагы турында ышандыру белдергән. 0 сәгать 55 минутта Германия сәүдә пароходының капитаны Германиянең Ослодагы миссиясенә 22 сәгаттә Англиянең „Коссек“ эсминецының „Альтмарк“ пароходын көчләп басып алганлыгын хәбәр иткән. Англичаннар һичбер нәрсә белән хисаплашмыйча мылтыклардан ата башлаганнан соң команданың бер өлеше пленгә алынган. Шушындый көчләү чаралары нәтиҗәсендә Германия командасы членнары арасында үлүчеләр һәм яралланучылар бар. Германия пароходы сайга утырган. 3 сәгать 05 минутта пароходның капитаны эсминецның боз өстенә төшкән һәм качарга урын эзләүче немец матросларына пулеметтан көчле ут ачканлыгы турында радио буенча хәбәр иткән. Германиянең үтерелгән коралсыз матросларының саны әле мәгълүм түгел. Пароход бортында 4 үтерелгән һәм 5 авыр яраланган кеше калган.

Шуннан соң Германиянең Ослодагы илчесе Норвегиянең чит ил эшләре министрлегенә протест нотасы тапшырды“.

КЫТАЙДА СУГЫШ ХӘРӘКӘТЛӘРЕН КҮЗӘТҮ

Япон гаскәрләре тарафыннан январь ахрында Гуанси провинциясендә Наньнин районында башланган һөҗүм бөтенләй уңышсыз тәмам булды. Бу һөҗүмнең беренче этапында японнарның ике колоннасы Наньниннан 50—60 километрга төньякка һәм төньяк-көнчыгышка таба китә алдылар һәм Умин, Биньян шәһәрләрен ала алдылар. Ләкин японнарның үзәк колоннасының һөҗүме Наньниннан төньяк-көнчыгыштарак Куньлуньгуань тау юлы янында туктатылды. Кытай гаскәрләре бу урынны кулларында нык тоттылар.

Япон гаскәрләре 2 нче февральдә Биньянны алганнан соң кытайлар командованиесе дошманның бу группасын чолгап алу һәм аны тар-мар итү планын төзеде. Шуның белән бергә кытайларның аерым отрядлары Биньяннан көньяктарак японнар тылында актив хәрәкәт башладылар һәм японнарга өстәмә көчләр һәм сугыш кирәк-яраклары китерүгә комачаулык иттеләр. Бу хәл бу районда японнарның сугыш сәләтен шактый киметте һәм алар зур югалтуларга дучар булып ашыгып чигенә башладылар. Умин районында япон гаскәрләренә флангтан удар ясалды һәм алар да Наньниннан көньякка чигенергә мәҗбүр булдылар. Монда хәзер япон гаскәрләренең төп көчләре туплана. Кытайлар, каршы һөҗүмгә күчеп, Наньнинга якын ук килделәр һәм андагы япон гаскәрләрен чолгап алдылар. Алынган саннарга караганда, Биньян—Умин районнарында булган сугышларда японнарның 20 меңләп кешесе үтерелгән.

Төньякта, Суйюань провинциясендә февраль башында японнар көнбатышка таба тагын да алга киткәннәр иде. Алар Уюань һәм Линьхэ шәһәрләрен алып, Нинсә провинциясе чигенә үк якынлашканнар иде. Ләкин кытай гаскәрләре японнарны чигенергә мәҗбүр иттеләр. 12 нче февральдә кытай частьләре японнарга каршы каты сугыштан соң Линьхэгә керделәр. Японнар Уюаньга чигенәләр. Японнарга Баотоудан Уюаньга ярдәмгә җибәрелгән гаскәрләргә кытайлар һөҗүм ясадылар һәм аларны тоткарлап тордылар. Сугышлар Уюань районында бара.

Үзәк Кытайда Чжэцзян провинциясендә, Ханчжоу шәһәреннән көнчыгыштарак, Сяошань районында каты сугышлар бара. Бу сугышларда уңыш әле бер якта, әле икенче якта.

ТАСС. 18 февраль.

Казан пехота училищесендә чыга торган стена газетасының редколлегиясе Кызыл Армиянең һәм Хәрби Диңгез Флотының XXII еллыгына багышланган бәйрәм номерын чыгару эшендә. Сулдан уңга—А. Т. Башаков, Г. Г. Низамов, В. В. Иванов, артта басып торалар — Д. А. Долгополов, П. В. Пикулев иптәшләр. М. Солтанов фотосы.

КЫЗЫЛ АРМИЯНЕҢ ҺӘМ ХӘРБИ ДИҢГЕЗ ФЛОТЫНЫҢ XXII ЕЛЛЫГЫ АЛДЫННАН

ХӘРБИ ЭКСПОНАТЛАР КҮРГӘЗМӘСЕ

18 нче февральдә Кызыл Армия йортының кече фойесында данлыклы XXII еллыкка багышланган күргәзмә ачылды. Күргәзмә Казан Хәрби Пехота училищесе һәм Кызыл Армия йорты тарафыннан оештырылды. Хәрби экспонатларны эченә алган бу кызыклы күргәзмә ату кораллары, химия, инженерлык, мото-механика, элемтә бүлекләреннән һәм башка бүлекләрдән тора. Анда кул пулеметы һәм станковый пулемет, гади винтовка һәм снайпер винтовкалары, механик пычкы, өрелмәле резина көймәләр, шартлату машиналары, миналар, маскировка костюмнары, кыр телефоннары, Морзе аппараты, кыр радиостанциясе, яктылык-сигнал аппаратлары һәм башка күп төрле экспонатлар куелган. Шунда ук электромотор ярдәме белән пулеметларның ничек эшләве күрсәтелә.

Стеналарда сугыш эпизодларын күрсәткән картиналар һәм агулаучы матдәләр турында витриналар эленгән.

Күргәзмәгә килүчеләргә хәрби хәзерлекле экскурсоводлар тарафыннан аңлатмалар бирелә. Күргәзмәдә беренче ачылган көнне 700 дән артык кеше булды. Шәһәр предприятиеләреннән, уку йортларыннан, мәктәпләрдән походлар оештыру турында күп санда заявкалар алына.

Күргәзмә 6 нчы мартка кадәр эшләячәк.

Р. Н.

ТӘТЕШ ПЕДАГОГИЯ УЧИЛИЩЕСЕНДӘ

Тәтеш педагогия училищесендә укучылар оборона эшен үстерүдә шактый уңышларга ирештеләр. Училищедә укучы 345 кешенең 340 ы Осоавиахим оешмасында член булып тора. Оешма янында ПВХО, ГТО, ГСО, Ворошиловча атучылар һәм граната ыргыту түгәрәкләре эшли.

215 укучы „ПВХО“ значогына, 177 укучы „ГСО“ значогына, 60 укучы „Ворошиловча атучы“ значогына, 24 укучы „ГТО“ значогына нормалар тапшырдылар, 300 укучы граната ыргыту буенча теориядән норма тапшырдылар.

Кызыл Армиянең һәм Хәрби Диңгез Флотының XXII еллыгы хөрмәтенә 115 кеше „ПВХО“ значогына һәм 45 кеше „ГСО“ значогына нормалар тапшыруга хәзерләнәләр.

Ж. Булатов.

СӘНГАТЬ РАБОТНИКЛАРЫ БӘЙРӘМГӘ ХӘЗЕРЛӘНӘЛӘР

Татарстанның сәнгать работниклары Кызыл Армия юбилеенә ныклы хәзерлек алып баралар. Театрларда һәм Сәнгать Эшләре Идарәсенең үзендә оборона түгәрәкләре эшли. Сәнгать работниклары бу түгәрәкләргә зур кызыксыну белән йөриләр.

Кызыл Армия көне якынлашу уңае белән оборона темаларына лекцияләр оештырылды. Артистлар һәм башка сәнгать работниклары „Ворошиловча атучы“, „ПВХО“, „ГСО“ значокларына нормалар тапшыралар.

Бәйрәм көннәрендә сәнгать работниклары Кызыл Армия частьләрендә һәм Казан Кызыл Армия йортында данлыклы XXII еллыкка багышланган концертлар бирәчәкләр.

23 нче февральдә Казан дәүләт циркы бинасында сәнгать работникларының Кызыл Армия һәм Хәрби Диңгез Флотының XXII еллыгына багышланган шәһәр җыелышы булачак.

ТӨЗӘТҮ

Газетабызның 17 нче февраль номерының, 4 нче битендәге „Татар Дәүләт Опера театрында“ дигән информациянең беренче баганасындагы 3 нче абзацын түбәндәгечә төзәтеп укырга кирәк:

„Ирек“ операсы февраль революциясе көннәрендә Казаннан ерак түгел татар авылларының берсендәге вакыйгаларне, ярлыларның һәм батракларның большевик Шамиль җитәкчелегендә алпавытка каршы көрәш алып баруын һәм Октябрь революциясе көннәрендә авылда контрреволюция көчләренең җимерелүен, халыкның җиңү тантанасын күрсәтә“.

„Трансэнергокадр“ның
Казан Автомәктәбе
производстводан аерып һәм аермыйча укытып III нче класс шоферлар хәзерләү буенча 20 нче февральдән
КУРСЛАР АЧА
III нче класс шоферлардан II нче һәм I нче класс шоферлар хәзерләү курсларына укучылар алу дәвам итә.
Шоферлар хәзерләү һәм шоферларның квалификацияләрен күтәрү курсларына укучылар предприятиеләрдән бирелгән командировкалар белән генә алыналар.
III нче класс шоферлар хәзерләү курсларына хатын-кызлар командировкасыз да алыналар.
Казан, Банк урамы, 15. 314—2—1

„Союзутиль“ нең Татарстан республика һәм Казан шәһәре конторалары
Луковский урамындагы 2-30 нчы номерлы йортка
КҮЧТЕ
Телефон 42—01. 262—1

ДӘҮЛӘТНЕҢ „Кызыл Шәрык“ сыра заводы
0,5 һәм 0,6 литрлы
сыра шешәләре ала
Шешәләр оешмалардан—Тукай урамындагы 107 нче йортта, ә барлык гражданнардан—заводның Казандагы барлык сыра сату урыннарында алына. 298—3—1

Курсантлар урнаштыру өчен 3—4 ай срок белән ашыгыч рәвештә
БҮЛМӘЛӘР ҺӘМ ПОЧМАК УРЫННАР КИРӘК
Толстой урамы, 41. Татнаркомлесның кадрлар бүлеге. 293—2—2

ДӘҮЛӘТ ЦИРКЫ
Бүген һәм һәр көн Москваның Ленин орденлы Дәүләт циркы артистларының ГАСТРОЛЕ
СТРАТОС—3
Номерлар орденлы артист БАСТ җитәкчелегендә башкарыла. Аэропланда үлем элмәкләре һәм башка күп номерлар.
РСФСР ның атказанган һәм орденлы артисты М. ЗОЛЛО гастрольләре дәвам итә.
Уен кич 8 дә башлана.
Касса һәр көн көндез 11 сәгаттән 1 гә һәм кич 5 тән 9 га кадәр ачык.

ТАТАР ДӘҮЛӘТ ОПЕРА ТЕАТРЫ
Галиәсгар Камал исемендәге Татар Дәүләт Академия театры бинасында
—АНОНС—
ИРЕК операсы
Билетлар ТДАТ кассасында алдан сатыла.
Операга коллектив рәвештә килү өчен заявкалар алына. 2—1

ЗУР ДРАМА ТЕАТРЫ
20 һәм 21 нче февральдә
Бакчалар чәчәк ата
Бүген талон 105.
Спектакльләр кич 7 сәгать 30 минутта башлана. Билетлар көндез 11 сәгать 30 минуттан 2 гә һәм кич 5 сәгаттән 7 сәгать 30 минутка кадәр кассада сатыла.

Галиәсгар Камал исемендәге
Татар Дәүләт Академия театры
Бүген, 20 нче февральдә
Булак арты „республикасы“
Талон 121.
23 нче февральдә
ТУКАЙ
Талон 122.
Спектакльләр көндез 12 дә, кич 7 сәгать 30 минутта башлана. Касса һәр көн көндез 11 сәгаттән 2 гә һәм кич 5 сәгаттән 9 га кадәр ачык.
ТДАТ.

Совет Кинематографиясенең XX еллыгы уңае белән „ЭЛЕКТРО“ КИНО-ТЕАТРЫНДА югары фойеда, кино-проэкция аппаратлары күргәзмәсе
— ачылды —
Кич 5 сәгаттән 10 га кадәр ачык.
Күргәзмәдә „20 елда Совет кинематографиясе“ дигән темада лекция укыла.
„УНИОН“ КИНО ТЕАТРЫНДА югаргы фойеда, „Совет кинематографиясенең иң яхшы мастерлары“ дигән темада
— күргәзмә ачылды —
Кичке сеансларда Горький филармониясе артисты И. М. Воронцовский чыгышлары. 3—1

„ЭЛЕКТРО“ 12, 2, 4, 6, 8 һәм 10 да.	Яңа фильм ДҮРТЕНЧЕ ПЕРИСКОП
„УНИОН“ 12, 2, 4, 6, 8 һәм 10 да.	ЗАПОРОЖЕЦ ЗА ДУНАЕМ
„КЫЗЫЛ ЙОЛДЫЗ“ 12, 2, 4, 6, 8 һәм 10 да	ЧАПАЕВ
„Колхозник“ 4, 6, 8 һәм 10 да.	СОҢГЫ ТӨН
„ЧАТКЫ“ 6, 8, 9-30 да.	КАСТУСЬ КАЛИНОВСКИЙ
„ПИОНЕР“ 10, 11-30, 1, 2, 3-30, 5-30, 7-10, 8-50, 10-30 да.	Көндезге һәм кичке сеансларда ПАТРИОТ Көндез 1 сәгаттә мәктәпкә кадәр яштәге балалар өчен сеанс.
„РОТ-ФРОНТ“ 4, 6, 8, 10 да.	СТЕПАН РАЗИН
КУЛЬТУРА САРАЕ 5, 7, 9 да.	КОМСОМОЛЬСК

БЫЛБЫЛ ЧИТЛЕГЕНӘ КЕРГӘН КАРГАЛАР

Халык шагыйре Габдулла Тукай 1907 нче елда үзенең „Мөтәшагыйрьгә“ дигән шигырен бастырып чыгара. Ачы сатира белән тулган бу шигырьне ул түбәндәге ике юл белән бетерә:

„Тәшагер итмә зинһар, кермә шагыйрь битлегенә син
Кисәрләр койрыгыңны, кермә былбыл читлегенә син“ ди.

Шагыйрь бу шигырен кемгә карата язган? Кемнең койрыгын кисәрләр дигән? Кемгә ул шигырь язып маташмаска, кәгаз әрәм итмәскә киңәш иткән? Алай гына түгел, хәтта зинһарлап, ялынып сораган. Әйтегез зинһар, кем ул, шагыйрьлек битлеге киеп, кәперәеп, үз-үзен белми йөри? Кем ул, былбыл читлегенә кереп, аның тынычлыгын боза, оясын туздыра? Китерегез, бирегез, ул мөтәшагыйрьне! Без аның койрыгын кисәрбез. Без аны хрестоматия төзүчеләрнең бердәнбер „әдәби“ кораллары булган үтмәс кайчы белән кисәрбез. О, ул хрестоматиячеләр!.. Алар ул үтмәс кайчы белән бөтен нәрсәне кисәргә, кыркырга, кеше танымаслык хәлгә китерергә... һәм беркайчан да, бер кем алдында да җавап бирмәскә була дип уйлыйлар.

Бәлки шуннан соң ул, былбыл читлегенә кереп, тузынып йөрмәс. Узган - барганнар да аңа, бармак белән төртеп:

„Карагыз, ай сабыйлар, бу кешене, сезгә гыйбрәт бу“, диярләр.

Чыннан да, бу зур гыйбрәт булыр. Китерегез! Кисәбез!

Ләкин кем соң ул мөтәшагыйрь? Бәхетсезлеккә каршы, без аны белмибез. Г. Тукайның бер томлык „Сайланма әсәрләре“нә искәрмәләр язучы Х. Хисмәтуллин иптәш бу турыда ап-ачык итеп әйтә: „Тукайның бу шигырьне кемгә карата язуы билгеле түгел“ ди.

Булмаса, Г. Тукайның соңгы елларда басылып чыккан китапларын, җыентыкларын, хрестоматияләргә кергән шигырьләрен актарып карыйк. Шунда берәрсе „шагыйрьлек“ итмәгәнме?

Юк, бу мөмкин түгел! Моны эшләмәсләр. Вөҗданнары күтәрмәс. Чөнки бездә әдәби мираска, әдәби җәүһәрләргә хөрмәт гаять зур. Без халык шагыйре Г. Тукайны хөрмәт белән, олылап һәм тарихыбызда шундый бөек шагыйрьнең булуына горурланып, искә төшерәбез. Аның юбилейләрен бөтен ил белән үткәрәбез. Мәктәпләрне, урамнарны, авылларны, колхозларны аның исме белән атыйбыз. Менә озакламыйча аның академик басмасы чыгар. Аның һәр сүзе, һәр хәрфе, кулъязмасы белән бик нык чагыштырылып, дорфалар тарафыннан кертелгән үзгәрешләрдән, хаталардан тәмам арчылып чыгар. Ул чын академик басма булыр. Һәм озакламыйча социалистик Казаныбызның иң матур бер мәйданында аның һәйкәле куелыр. Без ул һәйкәлне — шагыйрьнең үлүенә 30 ел тулды дигән көнне бик зур тантана белән ачып җибәрербез...

Шулай да без аның соңгы елларда чыккан әсәрләрен актарып карыйк әле.

Менә „Миаубикә“ китабы (Татгосиздат басмасы, 1935 ел, җаваплы редакторы К. Шәйхи).

Бала чагында без, бу китапны укып, мескен Миаубикәне чын күңелдән кызганып, җылый идек, төннәр буе йоклый алмый идек. Хәзер инде бу басманы укыгач, безнең ачуыбыз гына килә. Миаубикәгә түгел, ә аңы бозып, мыскыллап, хурлап чыгаручыларга ачуыбыз килә.

Текстларны чагыштырып карыйк. Китап буенча сибелгән имла хаталарына, аерым сүзләрнең ялгыш язылышына игътибар итмибез. Бары тик текстны гына алабыз.

„Фани дөнья! Нинди эшләр
Эшлисең син—шак та кат!“— ди Тукай. Мөтәшагыйрьгә бу ошамый. Ул аны „төзәтә, матурлый“:

„ҮТТЕ дөнья! Нинди эшләр
ЭШЛӘДЕҢ син — шак та кат“,—ди ул.

Нинди „матур“, нинди „уңышлы“ стиль! Фани дөнья түгел, ә үтте дөнья. Бер генә сүз! Тукай иҗады бөтенләй „яхшыланып, канатланып“ киткән.

Мөтәшагыйрь илһам диңгезенә тәмам чума. Ул инде көчәнеп, азапланып Тукайга яңа строфа яза:

„Киттең инде дөньябыздан
Кызгана сине күңел,
Инде синнән курыкмыйлар
Кортлар да, тычканнар
түгел—,“ ди.

Шуннан соң ул „илһамның“ соңгы чигенә җитә... уңга-сулга селтәнеп, Тукайны кыркырга тотына. Һәм бик батырланып алты юлын сыза да ыргыта.

Юк, „Миаубикәнең“ бу басмасын укыгач, безнең ачуыбыз гына килә, нервларыбыз гына бозыла, Тукайча басылганын, бозылмаганын укыйсыбыз килә. Шуның өчен дә „Г. Тукайның“ „Сайланма шигырьләрен“ алабыз. (Татгосиздат, 1938 ел, төзүчесе Х. Хисмәтуллин, җаваплы редакторы Р. Ильяс).

Хисмәтуллин иптәш Тукай иҗады өстендә күп эшләгән, тикшеренгән кеше. Тукайның бер томлыгын да төзеп чыгарган. Шуның өстенә укытучы да. Юк, ул инде Тукай иҗадын бозарга һич тә ирек бирмәс!

Без, алдан ук шатланып, „Сайланма шигырьләрне“ алабыз. „Миаубикә“не укыйбыз. Ни күзебез белән күрик, Хисмәтуллин иптәш тә мөтәшагыйрь икән! Дөрес, ул, авызлыксыз илһам фантазиясенә бирелүдә, беренче мөтәшагыйрьдән күп калыша. Ләкин инде батырлыкта, гафу итегез, ул беренче урында. Ул „Миаубикә“нең ике бүлеген бер итеп, берсен тәмам юк хәленә китерә. Үтмәс кайчысы белән, шатырдатып ун юлын кисеп ыргыта.

Без күңелебезне тынычландыру өчен, шул ук китаптан „Шүрәле“не укыйбыз. Нинди матур, нинди гүзәл әсәр!.. Ләкин кинәт аптырашта калабыз. Хисмәтуллин иптәш тә әдәби фальсификациягә бирелгән, ул да Тукайны „төзәтә“:

„Бер вакыт чүт-чүт итеп
сайрый АГАЧТА кошлары,
Китә җаннарны кисеп,
ярып садаи хушлары“, ди.

Тукай „ходайның кошлары“ дип яза, ә мөтәшагыйрь аны „төзәтә“: „Бу нинди дини сүз! Кырып ташлагыз аны!“—ди ул. Һәм ул, ачуланып китеп, бу сүзне генә түгел, шуннан соңгы уналты юлны да кырып ташлый. „Тәбрик“ итәбез! Батырланып китеп, ничек инде сез үзегезнең „хөрмәтле“ каләмегез белән Тукай иҗадыннан „Шүрәле“не бөтенләй сызып ташламадыгыз? Шүрәле дә хорафәт бит, юк бит шүрәле!

Без, бу китапны читкә ташлап, икенчене алабыз. „Әдәбият—дәреслек“ (Татгосиздат, 1939 ел, төзүчесе Х. Сәлимев, җаваплы редакторы И. Гумирова).

„Шүрәле“не яңадан укып карыйбыз. Ай фантазия, ай талант! Кайдан гына килә илһам боларга!

Бу мөтәшагыйрь инде „агачта кошлары“ дип кенә калмый, ә „Карурман кошлары“ ди. Нинди тапкырлык! Тизрәк, тизрәк, бу сүзне сүзлеккә кертеп калыгыз! Онытылуы, югалуы мөмкин! Һәм ул да, батырлык күрсәтеп, унике юлны бугазлый, аннары „Пар ат“ ны эштән чыгара.

Без, иң соңгы өмет чаткысына ябышып, башка дәреслекләрне, башка хрестоматияләрне актарып карыйбыз. Кайсын гына карама, үтмәс кайчы эзе ярылып ята.

Кайдан туган бу мөтәшагыйрьлек, кайдан килеп чыккан!?

„Кем җигә безгә тәдәнни арбасы?
Кемгә лагнәт әйтәсе һәм каргасы?“

Бөек шагыйрьне, халык шагыйрен, безнең шагыйрьне бозарга кем хокук биргән аларга? Әдәби фальсификация белән маташырга кем кушкан?

Бозмагыз, хурламагыз Тукайны! Ул сезнең фальсификацияләрегезгә мохтаҗ түгел!

Әгәр инде тыңламыйсыз икән, ул чагында, иң кимендә, Тукайның „Мөтәшагыйрьгә“ дигән шигырен яңадан укып карагыз. Үтенәбез. Анда сезгә карата бик ачык киңәш бирелгән:

„Һөнәрләр күп җиһанда, син дә моннан башка һөнәр тап,
Чабатаң берлә нинди мәнфәгать бар соң әдәп таптап“.

Чыннан да, егетләр, башка бер һөнәр табыгыз, бозмагыз Тукайны!

Афзал Шамов.

Җаваплы редактор
һ. АБДРАХМАНОВ.
Ответ. редактор Х. АБДРАХМАНОВ.

УПОЛН. ГЛАВЛИТА ТАССР. № А — 249 ТИПОГРАФИЯ ИМЕНИ АЛЕКСАНДРОВА. ДОМ ПЕЧАТИ 1940 ГОД. ЗАКАЗ № 677.